ФГАОУ ВПО “Казан (Идел буе) федераль университеты”

Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү үзәге

Р.К.Шаехова, Г.М. Газизуллина

# СЕРЛЕ ИҖАТ ЧИШМӘСЕНӘ КЫЗЫКЛЫ СӘЯХӘТ

## Тәрбия һәм белем бирү процессында якташыбыз Фәнис Яруллинның әсәрләрен файдалану

Казан – 2014



Фәнис Яруллин 1938 елның 9 февралендә Баулы районы Кзыл-Яр авылында, игенче гаиләсендә туа. “Туган авылым Кзыл-Яр – табигатьнең матур җиренә урнашкан. Бакча ягында Ык елгасы агып ята. Ыкның аргы ягында таулар башлана. Таулар итәгендә сандугачлы-җырлы әрәмәләр җәелеп киткән...

...Туган ягым Баулы ягым
Җаннарыма җылы ягым.”

дип искә ала шагыйрь үзенең туган ягын.

1957 елда ул армия сафларына алына. Спорт күнегүләрнең берсендә турниктан егылып имгәнә. Шушы көннән соң аның бөтен тормышы, яшәү рәвеше үзгәрә. Көтелмәгән бу бәхетсезлек белән ул көне- төне көрәшеп яшәргә мәҗбүр була. Фәнис Яруллин минут саен, сәгать саен зур ихтияр көче, рух ныклыгы сорый торган язмыш белән яши башлый. Шул елларда шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр иҗат итә башлый.

Урын өстендә, шифаханәләрдә озак ятуына карамастан, ул аң-белемгә омтыла. Читтән торып Казан Дәүләт университетын тәмамлый.”Мин авыруга бирешергә тиеш түгел”- дигән фикер аның күңеленә ныклап урнаша. Ул үзенең барлыгын әдәбият аша белдерергә тели. Язучы эше аңа тормышта кешеләр белән бәйләнеш тоту чарасына әверелә. Тыңларга теләмәгән кулларына каләм алып язу аның өчен энә белән кое казудан да авыррак була. Тормыш нинди генә сынаулар аша уздырса да:

Алтыннан кече түгел мин,
Ипидән олы түгел.
Үлемнән көчле түгел мин,

Тик язмыш колы түгел. - дип әйтергә шагыйрь үзендә көч таба.

Фәнис Яруллинның илледән артык китабы дөнья күрде. Аның иҗат чишмәләре төрле халык телләренә тәрҗемә ителеп тә, төрле газета-журналларда да басылып тора. Шагыйрьнең юмористик шигырьләрен укыганда аны дөньясы җиткән, тәне сау-сәламәт, шаянлыгы ташып торган кеше дип уйлыйсың.

“Мин гомерем буе тормыш авырлыкларын шигъри канатларымда күтәреп барам. Дөрес, кайвакыт бу канатлар өзелеп төшәрдәй булып ала, кыяларга бәрелеп яралана, давылларга очрап каурыйлары йолкына. Мондый чакта берәр кыяга башны салып ял итәсе килә. Ләкин ярамый, мин бары тик очышта гына яши алам. – **Минем матурлыгым очышта**”, - дип яза Фәнис Яруллин.

Шагыйрьнең фаҗигале тормышында янәшәсендә таш кыядай нык булып, олы җанлы Нурсөясе тора. Мәхәббәт белән яшәү, гаилә бөтенлеге аны бәхетле итә, иҗатына дәрт өстәп тора. Нурсөя ханым-шагыйрьнең гомерлек тормыш иптәше, ярдәмчесе. Фәнис ага үзе дә: “Минем шәфкать туташым да, секретарь-машинисткам да, шоферым һәм сөйгән ярым да – Нурсөя” ди. Шагыйрь аңа үзенең иң матур шигырьләрен багышлаган.

Чәчмә, сәхнә әсәрләре авторы, татар халкының корыч ихтиярлы ир-егете, Муса Җәлил, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре лауреаты, Татарстанның халык шагыйре, әдип, халкыбызның каһарман улы Фәнис Яруллин үзенең иҗаты белән безне дөнья ваклыкларыннан, вакытлыча булган ыгы-зыгылардан өстен булырга өйрәтә, чын мәгънәсендә **Кеше** булырга чакыра. Тормыш сынауларына бирешмичә яшәгән әнә шундый кешеләрне корыч ихтыярлылар дип әйтәләр. Фәнис ага Яруллин әнә шундый кешеләрнең берсе!

Дөньяда бар төрле чишмә.
Шуның берсе серле чишмә.
Суы тирән – төпсез аның.
Юлы ерак – чиксез аның.

Олыга да, кечегә дә
Батыр, көчле кешегә дә
Бу чишмәнең татлы суы
Бик тә кирәк гомер буе.
Әгәр кеше юлга чыкса,
Юлга ала аның суын.
Серле чишмә суы белән
Ләззәтләнгән күпме буын.
Бу чишмәнең суын әле
Бездән соң күпләр эчәсе.
Саекмасын, гел саф калсын
Серле чишмә - тел чишмәсе.

*Фәнис Яруллин.*

**Проектның** тулы исеме:
**“Серле иҗат чишмәсенә кызыклы сәяхәт”**
(Белем бирү һәм тәрбия процессында якташыбыз **Фәнис Яруллин** әсәрләрен файдалану)

**Проектның кыскача эчтәлеге:**

Татарстан Республикасы халыклары телләре турында”гы Закон Татарстан халыкларының телләрен һәм мәдәниятен һәръяклап тирәнтен үстерүне, җәмгыятебезнең үсешендә һәр милләтнең иҗади куәтен, гореф – гадәтләрен, йолаларын мөмкин кадәр күбрәк, нәтиҗәлерәк куллануны күз алдында тота.

Татар теле - бик борынгы һәм бай телләрнең берсе. Тел һәрбер халыкның узара аралашу, дөньяны танып – белү чарасы, фикерләү – уйлау коралы булып та хезмәт итә. Теле аша халык үзенең кайгы – шатлыкларын, хыялларын, теләкләрен белдерә. Әби – бабаларыбыз безгә бүтән байлыклар белән тел хәзинәсен дә бүләк итеп варисларына тапшырып килә.

Балалар бакчасында проектлар методын файдалану балага шәхси якын килеп белем һәм тәрбия бирүдә нәтиҗәле технологияләрдән санала; баланың акыл һәм рухи үсешен камилләштерергә ярдәм итә; анда максатчанлык, кызыксынучанлык, башлаган эшне ахырына җиткерү

омтылышы тәрбияли, баланың ана телендә һәм башка телдә аралашу осталыгын арттыра.

Проект эшчәнлеге күмәк рәвештә иҗади хезмәт башкару күнекмәләре формалаштыра, төрле мәдәниятләр арасындагы бәйләнешне тоярга, аңларга ярдәм итә. Проект алымы – баланың аны урап алган мохит, тирә- юнь белән таныштырганда кулланыла. Үзебезнең төбәккә генә хас булган җирле үзенчәлекләрне, йолаларны төгәл белү өчен милли төбәк компонентын дәресләргә кертәбез: милли төбәк компоненты кысаларында “Серле иҗат чишмәсенә кызыклы сәяхәт” - дип исемләнгән проект төзедек.

**Проектның төп бурычлары:**

– балаларда татар теле өйрәнүгә, татар халкының тарихы, гореф – гадәтләре, мәдәнияте белән кызыксынуга омтылыш тәрбияләү;

– баланың акыл һәм рухи үсешен камилләштерү;

– туган як табигатенә мәхәббәт хисләре тәрбияләү;

– танылган якташларыбызга ихтирам тәрбияләү, язучы Ф. Яруллинның тормышы һәм иҗаты белән таныштыру;

– сүзлек запасларын арттыру;

– сөйләм телләрен камилләштерү;

– монологик, диалогик сөйләм формалаштыру;

– туган як табигатенә күзәтүчәнлек, аның гүзәллегенә соклану, җаваплылык хисләре тәрбияләү;

– халыкның зирәк акылын, тәҗрибәсен, сәләтен, хыял - өметләрен, дөньяга карашын, яшәү рәвешен чагылдырган әсәрләр белән таныштыру.

**Проектта катнашучылар:** балалар, ата – аналар, татар теле тәрбиячеләре, музыка җитәкчеләре, сүрәтләү эшчәнлеге тәрбиячесе.

**Проектны гамәлгә ашыру вакыты:** 2010-2011 еллар.

**“Серле иҗат чишмәсенә кызыклы сәяхәт” проектын тормышка ашыру стратегиясе**

| Программа өлешләре | Эш төрләре һәм алымнары |
|---|---|
| I блок<br>Әхлак тәрбиясе | Максат:<br>Балалар арасында дустанә мөнәсәбәт булдыру. Гаделлек, тыйнаклык, ярдәмчелек, кеше хәленә керә белү кебек сыйфатлар формалаштыру. Сөйләм әдәбенә өйрәнү эшен дәвам итү. Сөйләмдә “исәнмесез”, “сау булыгыз”, “зинһар”, “гафу итегез” “рәхмәт” кебек сүзләре куллану, активлаштыру.<br>Тирә- юн чынбарлыкка үз мөнәсәбетеңне белдерә һәм аны аңлатуга омтылыш тәрбияләүне дәвам итү.<br>1. “Алабай белән Соры” әкияте<br>“Зәңгәр күлдә ай коена” китабы. – Казан, 1990 ел.<br>2. Ике тамчы “Гөлбакча” Казан, 1990 ел.<br>3. “Муму” хикәясе.<br>“Нәниләргә бүләк” китабыннан. - Казан, 1988 ел. |
| II блок<br>Нәфасәти үсем мөхите | Максат:<br>Әйләнә - тирәнең матур, күзне сөендерә торган, компонентларын аерырга өйрәтү; татар-халык музеендагы халык-сынлы сәнгате предметлары; үзең сайлаганны нигезләү, әйләнә-тирәлекне нәфасәти яктан бәяли белү. Балаларны төркемдә якташларыбыз, яраткан шагыйрьләребез почмакларын оештыруга, мөстәкыйль иҗади эшчәнлек өчен материалларны урнаштыруга тарту.<br>1. “Туган телем-иркә гөлем” төркемнәрдә милли почмаклар булдыру. |

| | |
|---|---|
| | 2. “Туган якны өйрәнү” шәһәр музеена барып, сәнгать әсәрләрен карау. |
| III блок<br>Уен эшчәнлеге | **Дидактик уеннар**<br>1. “Сүз остасы”<br>Максат: Мәгънәсе белән башка бер сүзнең капма-каршысын белдерә торган сүзләр табу; аваз составы үзгә, ә мәгънәләре бердәй яки якын булган сүзләр табу; ике сүз белән аталган предметларны әйтә белергә өйрәнү.<br>2. “Тиз җавап бир”<br>Максат: Балаларны чагыштыра, гомумиләштерә белергә өйрәтү, сүз байлыгын арттыру.<br>3. “Китапханә”<br>Максат: әйләнә-тирә белән танышу, әдәби-әсәрләр укудан алган белемнәрен уеннарның сыйфатын үстерүдә, эчтәлеген баетуда киңрәк һәм иҗади якын килеп файдаланырга өйрәтү. Уен ярдәмендә балаларның фантазиясен баету, сәләтләрен үстерү. |
| IV блок<br>Театральләштерү эшчәнлеге | Максат: Балаларда милли мәдәният турында бербөтен күзаллау булдыру, туган телеңне белү һәм шул телдә аралашуга кызыксыңу тәрбияләү<br>• Балаларда театр культурасы күнекмәләре тәрбияләү, әсәрләрне сәхнәләштергәндә балалар һәм өлкәннәрнең үзара йогынтысының төрле формаларын куллану.<br>• Сәхнәләштерү өчен мөстәкыйль рәвештә экият, шигырь, җырлар сайлый белү.<br>• Сәхнәләштерүнең сәнгати чараларын (гәүдә торышы, мимика, хәрәкәтләр) |

| | |
|---|---|
| | куллану.<br>Фәнис Яруллин әкиятләре:<br>“Зәңгәр күлдә ай коена”, “Кызыл алма”, “Тиен малае Тим-тим”, “Баз бакасы”. |
| V блок<br>Ата-аналар белән эш | **Мәгълүмәти-аналитик хезмәттәшлек**<br>1. Анкеталар, тестлар, ата-аналар арасында сорашулар үткәрү.<br>**Үзара хезмәттәшлек**<br>1. Ата аналар белән конференция: “Гаилә кунакханәсендә”.<br>2. Якташ язучыбыз Ф.Яруллин белән очрашулар.<br>3. “Гаилә эмблемасы”, “Шәҗәрә агачы” бәйгеләре.<br>4. “Әбиемнең сандыгы” – борынгы милли киемнәр, кул эшләре күргәзмәсе.<br>**Күрсәтмәлелек эшчәнлеге:**<br>1. “Күчмә папкалар” (“Әдәплелек дәресләре”).<br>2. Ата-аналар өчен консультацияләр: “Сөмбелә-милли бәйрәм”, “Балаларда әхлак сыйфатлары тәрбияләүдә Ф.Яруллин әсәрләренең роле”.<br>3. Ата-аналар белән бердәм чаралар календаре.<br>4. Газеталар чыгару “Крепыш”.<br>**Күңел ачу чаралары.**<br>“Аталар сүзе-акылның үзе”-әтиләр бәйрәме.<br>“Чәй яны-гаилә җаны”- өлкәннәр бәйрәме.<br>Татар халык уеннарыннан төзелгән спорт бәйгесе.<br>“Туган тел чишмәләре” драмматүгәрәгенең эшендә катнашу, костюмнар, декорацияләр, маскалар әзерләү. |

| | |
|---|---|
| VI блок<br>Әйләнә-тирә табигать.<br>Экологик тәрбия | Максат:<br>Балаларны табигатьтәге үзгәрешләр, экологик бәйләнешләр белән таныштыру эшен дәвам итү, аларда табигатькә аңлы караш тәрбияләү. Табигатьтә үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләрен ныгыту. Сөйләм телен үстерү.<br>Шигырьләр:<br>“Март кояшы”, “Апрель”, “Май”, “Июнь-июль”, “Август”, “Сентябрь”, “Суык төсе”.<br>Яруллин Ф.Г. Шигырьләр, экиятләр, поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996- 48-51 бит. |

**“Серле иҗат чишмәсенә кызыклы сәяхәт” проекты буенча перспектив план**

| | Уртанчылар төркеме | Зурлар төркеме | Мәктәпкә әзерлек төркеме |
|---|---|---|---|
| Октябрь | 1.Ф.Яруллиның тормыш юлы белән таныштыру.<br>“Түтәлдә үскән суган...” шигырен уку. | 1. Ф.Яруллиның тормыш һәм иҗат юлы белән таныштыруны дәвам итү. “Сентябрь”, “Октябрь” шигырьләрен уку.<br>2. Көз турында әңгәмә, табигатьтәге үзгәрешләрне чагыштыру. “Октябрь” | Балаларның Ф.Яруллин турында алган белемнәрен ныгыту һәм баету. Шаян шигырьләре белән таныштыру: “Охшашлык”, “Композитор чыпчыклар”, “Әллә кайчан”. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | шигырен ятлау. | |
| Ноябрь | | 1. “Кызыл алма” экиятен сөйләү.<br>2. Әкият эчтәлеге буенча әңгәмә, экиятне балалардан сөйләтү. | “Зәңгәр күлдә ай коена” экиятен сөйләү. |
| Декабрь | “Бик ачу килә кышка” шигырен уку. | 1. Кыш турында шигырьләрен уку: “Бияләй”, “Суык төсе”, “Кыш башы”.<br>2. Кыш турында әңгәмә “Бияләй”<br><br>шигырен ятлау. | “Соры һәм Алабай” экиятләрен сөйләү. |
| Гыйнвар | | | “Тиен малае Тим-тим” экиятен сөйләү. |
| Февраль | 1. Кошлар турында әңгәмә. “Чыпчык” шигырен уку.<br>2. “Чыпчык” шигырен ятлау. “Ч” авазы. Аваз культурасы. | 1. Йорт хайваннары турында әңгәмә “Муму” хикәясен уку.<br>2. “Муму” хикәясе буенча әңгәмә. Тырышлык турында мәкальләрне истә калдыру. | Ф.Яруллин экиятләре, шигырьләре буенча викторина. |
| Март | Әбиләр, әтиләр турында әңгәмә. “Әби килде | Әбиләр, әниләр турында әңгәмә. “Бушлык” | 1. Яз турында әңгәмә “Кая киткән |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | авылдан” шигырен ятлау. | шигырен ятлау. | тамчылар” шигырен ятлау. 2. “Ике тамчы” экиятен сөйләү. Шигырьне кабатлау. |
| Апрель | | Кошлар турында әңгәмә. “Композитор чыпчыклар” шигырен уку, ятлау. | Татарстан байрагы һәм гербы турында әңгәмә. Ф.Яруллин “Татарстан байрагы” шигырен уку. |
| Май | | 1. Ф.Яруллин турында белгәннәрен гомумиләштерү. “Кояштагы тап” әкиятен сөйләү. 2. “Кояштагы тап” әкиятен балалардан сөйләтү. | 1. Тәрбиячеләр, ата-аналар әзерләгән “Баз бакасы” әкиятен сәхнәләштерү. 2. “Баз бакчасы” әкиятенең эчтәлеге буенча әңгәмә. |

**Проектны гамәлгә ашыру механизмы (алымнары)**

– әңгәмәләр, күзәтүләр;
– бәхәсләр;
– диспутлар;
– күмәк – иҗади чаралар;
– конкурслар;
– очрашулар;

– экскурсияләр, походлар;
– тестлар;
– туган тел атналары;
– педагогик һәм ситуатив биремнәр;
– конференцияләр;
– шөгыльләр (комплекслы, тематик, интеграль);
– әсәрләрне сәхнәләштерү.

**Ата-аналар һәм балалар белән эшне тормышка ашыру.**

| Ата-аналар белән эш | Балалар белән эш |
|---|---|
| – Ата-аналар белән конференция: “Гаилә кунакханәсендә”.<br>– Ф.Яруллин белән очрашулар.<br>– “Туган тел чишмәләре” драмтүгәрәгенең эшендә катнашу, костюмнар, маскалар декорацияләр әзерләү.<br>– Ата-аналар өчен анкеталар.<br>– Аталар сүзе – акылның үзе - этиләр бәйрәме.<br>– “Чәй яны – гаилә җаны” өлкәннәр бәйрәме. | – Танып белү дәреләре.<br>– Ф.Яруллин әсәрләрен сәхнәләштерү.<br>– Ф.Яруллин әсәрләре буенча викториналар.<br>– Музыка дәресләре.<br>– Борынгы онытылган уеннар уйнау.<br>– “Сөмбелә”, “Нәүрүз”, “Карга боткасы” бәйрәмнәре.<br>– Татар халык уеннарыннан төзелгән спорт бәйгесе.<br>– “Туган ил кайдан башлана” – дәрес. |


Ата-аналар белән кумәк эш алып бару
Анкетирование, тестлар, диспутлар
“Ата-аналар почмаклары”н тулыландыру, баету
Фотосурәтләр, видеоязмалар, әсәрләр буенча рәсемнәр булдыру
Шәһәр, Кзыл-Яр авылы музейларына кумәк экскурсияләр
“Туган тел” атналары, “Ачык ишек” көннәре
Куренекле якташларыбыз белән очрашулар
Семинарлар, викториналар
Түгәрәк өстәл «Гаилә кунакханәсендә”
Тикшерену, практик эшләр буенча педагогик биремнәр
Телефон, интернеттан аралашулар
Максатлы походлар
Педагогик китапханәләр
Әсәрләрне сәхнәләштеру өчен костюмнар тегу, атрибутлар ясау
Проектның максатлары белән таныштыру


Балалар белән күмәк эш төрләре һәм алымнары
Күзәтүләр
Эзләнеп тикшеренү, танып белү, мөстәкыйль сәнгать эшчәшлеге
Сөйләм теленнән үстерешле уеннар
Театрләштергән тамашалар
Табышмаклар кичәсе
Уеннар: сюжетлы-рольле, хәрәкәтле, дидактик, сәхнәләштерелгән
Кроссвордлар белән эш
Әйләнә-тирә белән таныштыру
Хезмәт эшчәнлеге
Сүзлек өстендә эш
Шигырьләр ятлау
Әңгәмәл
Мини викторина
Музыка эшчәнлеге:КВН,музыкаль әкиятләр, милли бәйрәмнәр
Матур әдәбият әсәрләрен уку
Рәсемнәр, китаплар карау
Шәһәр, мәктәпләр, Кзыл-Яр авылы музейларына күмәк экскурсияләр
Блиц турнирлар

**Проект эшчәнлекне тәэмин итү**

**1. Методик әсбаплар:**

– Тормыш юлын чагылдырган фотоальбом, видеоязмалар;

– “Бәхетле очрашу мизгелләре” – фотоальбом, видеоязмалар;

– Әкиятләр эчтәлеге буенча төсле иллюстрацияләр;

– Әсәрләрне сәхнәләштерү өчен җиһазлар;

– Әсәрләр буенча картиналар;

– Якташыбызның әсәрләрен сәхнәләштерү видео/язмалары

– “Полеты Фаниса Яруллина” – режиссер Ә.Габдрахманов. Казан 2008 год – видеофильм язмасы.

**2. Фәнис Яруллинның әсәрләре исемлеге** *(безнең кулланышта булганнары)* **:**

– “Мин тормышка гашыйк”( татар һәм рус телләрендә нәшер ителгән әсәр) – 1961 ел.

– “Аерылмас дустым” – 1975 ел

– “Сулыш” – 1978 ел

– “Тозлы тамчы” – 1988 ел

– “Зәңгәр күлдә ай коена” – 1990 ел

– “Йөз аклыгы” – 1994 ел

– “Гамьле дөнья” – 1994 ел

– “Чәчәкләр моңы” – 1994 ел

– “Яз гөлләре” – 1996 ел

– “Биюче бака” – 1996 ел

– “Яралы язмышлар” – (татар, рус һәм инглиз телләрендә нәшер ителгән әсәр) 2000 ел

– “Урман кызы” – 2001 ел

– “Сандугач оясы” – (татар һәм латин телләрендә нәшер ителгән әсәр) 2002 ел

– “Шәфәкъ вакыты” – 2003 ел

– “Сөенечләр бүлешү” – 2003 ел

– “Әсәрләр”(өч томда) – 2008 ел

– “Яз кайда кышлый” – (татар һәм рус телләрендә нәшер ителгән әкиятләр җыентыгы) 2009 ел

**Көтелгән нәтиҗәләр.**

Рухи байлыгына хәзинә итеп караучы, аны кадерләп саклаучы, тел байлыгын үстерә һәм буыннан буынга тапшыра баручы шәхес тәрбияләү. Танылган якташларыбызга ихтирам тәрбияләп, аларның әсәрләре үрнәгендә туган телебезнең күркәм үрнәкләрен, әхләкый тәрбиядә файдалану.

Халыкның тарихы белән тыгыз бәйләнештә торган халкыбызның гореф-гадәтләрен, йолаларын өйрәнүне тәэмин итү.

**Проектның перспективасы**

Перспектив планны тулыландыру, яңа иҗат ителгән әсәрләрен өстәү. Балаларның яшьләренә карап шәхси якын килү.

Мәктәптәчә яшьтәге балаларга үзләштерү өчен җинел булган әсәрләрен җыйнап шул әсәрләрне тулысы белән кертеп дәрес эшкәртмәләре җыентыгын чыгару.

Проектны гамәлгә ашыру перспективасы спонсорлар һәм бюджеттан тыш керемнәр ярдәмендә күздә тотыла.

## Проектны тормышка ашыру нәтиҗәләре Фәнис Яруллинның әсәрләре нигезендәге сайланма шөгыльләр эшкәртмәләре

**Тема: Якташыбыз.**

**Фәнис Яруллин иҗаты белән таныштыру.**

***Уртанчылар төркеме.***

**Максат:** Балаларны татар язучылары белән таныштыруны дәвам итү, аларның иҗатына кызыксыну, мәхәббәт тәрбияләү, якташыбыз белән горурлану хисләре уяту.

**Алдан эшләнәсе эшләр:** Габдулла Тукайның һәм Абдулла Алишның программадагы әсәрләре белән таныштыру. “Миңлебай” уенын өйрәнү.

**Күргәзмә әсбаплар:** Фәнис Яруллин портреты, альбом, әсәрләр җыентыклары.

**Дәрес барышы:**

– Балалар, искә төшереп үтик әле, сез татар язучыларыннан кемнәрне беләсез? (Г.Тукай, А.Алиш). (Г.Тукайның “Ак бабай”, “Гали белән кәҗә” шигырьләре, “Су анасы” әкияте, А.Алишның “Куян кызы”, “Бикбатыр белән Биккуркак”, “Чукмар белән Тукмар” әкиятләре)

– Җавапларны тулыландыру, гомумиләштерү.

– Ә бүген мин сезне бер язучы белән таныштырам. Ул-Фәнис абый Яруллин (Портретын күрсәтү).

– Ә сезнең кебек кечкенә чакта Фәнис абый Баулыда бик еш булган, чөнки ул – безнең якташыбыз. Кызыл-Яр авылында туып үскән. Ул авылда Ык елгасы бар. Кечкенә Фәнис ул елгада су коеныирга, балык тотарга, ярында кызыныирга яраткан. Ул Кызыл Яр мәктәбендә укыган. Яшьтән ук акыллы, тырыш булып үсә, яхшы билгеләргә генә укый, спорт белән шөгыльләнә, очучы булырга хыяллана.

– Хәзерге вакытта Фәнис абый Казан шәһәрендә яши. Ул балаларны бик ярата. Алар өчен шигырьләр, әкиятләр яза (җыентыкларын күрсәтү).

– Ә сезнең кебек кечкенә чакта Фәнис абый “Миңлебай” уенын яратып уйнаган. Без дә уйнап алабызмы? “Миңлебай” уены (Программа 65 бит.)

Уеннан соң “Әби килде авылдан”, “Әнисен Ләйлә...” шигырьләрен уку.

– Җәй көннәрендә Фәнис абый Кызыл Ярга кунакка кайта. Бер кайтуында ул үзе белән Сим-Сим исемле песиен дә алып кайткан иде. Ул аны әнисендә калдырып китә дә, кайткач сагынып аның турында шигырь яза.

***“Батыр песи”*** шигырен уку.

**Б**езнең Сим-Сим миннән батыр
Бөтен яктан.
Ул караңгыдан курыкмый,
Ә мин куркам.

Ул еланнардан курыкмый,
Ә мин куркам.
Менә шундый батыр була
Алсаң иде.
Караңгыда курыкмыйча
Калсаң иде.

*Сораулар:*
1. Балалар, шигырьләр ошадымы сезгә?
2. Ул шигырьләрне кем язган?

**Дәрескә йомгак ясау.**
*Шигырьләр:*

***Әби килде авылдан...***
Әби килде авылдан.
Безне бик тә сагынган.
Без дә аны сагындык –
Күчтәнәчкә сарылдык.

***Әнисен Ләйлә...***
Әнисен Ләйлә
Шундый ярата:
Елап каршылый,
Елап озата.

**Тема: Әбиләр турында әңгәмә.**

**Фәнис Яруллинның "Әби килде авылдан" шигырен ятлау (уртанчылар төркеме өчен)**

**Максат:** Балаларга әбиләрнең безнең өчен иң якын, иң кадерле, иң назлы кеше булуын, аларны зурларга, хөрмәтләргә, алар турында кайгыртырга, аларга ярдәм итәргә кирәклеген аңлату. Якташыбызның иҗаты белән кызыксынуны дәвам итү. Шигырьне яттан сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтү.

**Алдан эшләнәсе эшләр:** Музыка дәресләрендә "Минем әби" җырын өйрәнү (А.Ключарев, көе, Г.Латыйп шигыре).

**Сүзлек:** күчтәнәч, сарылдык, якташ, шагыйрь.

**Дәрес барышы:** Әбиләр турында кыскача әңгәмә.

1. Балалар, сезнең әбиләрегез бармы?
2. Сез аларны яратасызмы?
3. Ни өчен яратасыз?
4. Әбиләрегезгә кунакка барасызмы?
5. Аларга булышасызмы?
6. Алар сезгә кунакка киләләрме?
7. Нәрсә алып киләләр?

– Җавапларны тулыландырып сөйләү.

– Әбиләр безнең өчен иң кадерле кешеләр. Алар олы җанлы, киң күңелле, тәмле телле, йомшак куллы. Аларның ак чәчләреннән сыйпасы, матур сүзләр әйтеп юатасы, рәхмәтләр әйтәсе килә.

– Әйдәгез әле “Минем әби” җырын җырлап алыйк.

Әбием күзлек кия,
Чәчләренә ак кунган.
Бер көн дә соңга калмый,
Иртүк тора йокыдан.

Кушымта:

Әбекәй, алтыным,
Минем иң якыным,
Яратам, яратам
Мин аны.
Минем әби энемне
Бәй-бәй этә, пәп итә.
Ул йокыдан торганда,
Мәмие пешеп җитә.

Кушымта: шул ук

Ул мине дә үстергән,
Апамны да пәп иткән.
Ул хәзер пәп иттерми,
Апаем буйга җиткән.

Кушымта:

– Җырны җырлаганда хәрәкәтләр дә күрсәтеп, физминут урынына кулланырга.

– Якташыбыз Фәнис Яруллин да әбиләр турында шигырь язган.

Әби килде авылдан
Безне бик тә сагынган
Без дә аны сагындык
Күчтәнәчкә сарылдык

– Сәнгатьле итеп сөйләү.

Сораулар:

1. Әби кайдан килде?
2. Ул авылдан нәрсә алып килә?
3. Сез дә әбиләрегезне сагынасызмы?
4. Алып килгән күчтәнәчләре тәмлеме?

– Шигырьне кабат сөйләү. 4-5 баладан сөйләтү.

**Йомгаклау.**

**Тема: "Кояштагы тап" әкиятен сөйләү.**

**Фәнис Яруллин турында белгәннәрне гомумиләштерү.**

***Өлкәннәр төркеме өчен.***

**Максат:** Якташыбыз турында белгәннәрне искә төшерү, ныгыту. Әкиятнең төп идеясын: кешелекле, өлкәннәргә ихтирамлы, шәфкатьле, миһербанлы булырга кирәклеген аңларга булышу. Сорауларга тулы җавап бирү, сөйләм телен үстерү өстендә эшләү. Фәнис Яруллинның иҗатына кызыксыну уяту.

**Сүзлек:** чишмә, чиләк, болыт, офык, шифалы.

**Шөгыль барышы:** Фәнис Яруллинның тормыш юлы турында белгәннәрне кыскача искә төшерү. "Бияләй" шигырен, "Муму" хикәясен искә төшереп үтү. Якташыбызның шигырьләр,

хикәяләр генә түгел, әкиятләр дә язганын әйтеп, “Кояштагы тап” әкиятен сөйләү.

**Сүзлек өстендә эш.**

**Физминут “Кояш”** *(Балалар чүгәләп утырганнар)*

“Кояш күтәрелә” – *балалар әкрен генә торалар, кулларын өскә күтәрәләр.*

“Кинәт җил чыкты” – *уңга-сулга кулларын чайкыйлар.*

“Яшен яшьнәде” – *уңга-сулга кул чабалар.*

“Яңгыр ява башлады” – *чүгәләп, бармак очлары белән идәнгә чиртәләр.*

“Яңгыр туктады” – *балалар торып басалар.*

“Яңадан кояш чыкты” – *кулларны өскә күтәрәләр.*

**Сораулар:**

1. Малайның әнисе нигә авырды икән?
2. Малай әнисен ратканмы?
3. Яраткан кешене алдап буламы?
4. Малай үзенең дөрес эшләмәгәнлеген аңлыймы?
5. Аңлаганын каян белдек?
6. Шулай да малайны бик начар дип әйтә алабызмы?
7. Ничек уйлыйсыз, ул моннан соң әнисенә ярдәм итәр микән?
8. Бу әкият безне нинди булырга өйрәтә? (кешелекле, намуслы, ярдәмчел, тәүфыйклы, миһербанлы). *Бу сүзләрне тагын бер кат аңлатып, кабатлатлау.*

**Йомгаклау.**

Безнең якташыбыз Фәнис абый балалар өчен шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр яза. Ул балаларны бик ярата. Балалар тәүфыйклы, ярдәмчел, кешелекле булып үссеннәр дип тырыша. Без шундый якташыбыз булуы белән горурланабыз. Аңардан яңадан-яңа әсәрләр көтеп калабыз.

**“Кояштагы тап”**

*Фәнис Яруллин әкияте*

Еракта, бик еракта, Каф тавының аръягында, кояш һәркөн йокларга кайта торган җирдә яшәгән, ди, бер малай. Малайның бары тик әнисе генә булган, ди. Малайның әнисе кояш белән

бергә торган, кояш белән бергә яткан. Ул көннәр буе нидер чәчкән, нидер урган, нидер төзәткән, нидер яңарткан. Ә улы аңардан юри генә дә:

– Әнием, син көннәр буе бил турайтмыйчаниләр эшлисең? – дип сорамаган, гел уйнаган да уйнаган.

Менә көннәрдән бер көнне малайның әнисе авырып түшәккә егылган. Шунда ул урамда болытларга ук атып йөрүче улын өенә чакырып керткән дә болай дигән:

– Улым, үзең күрәсең, хәлем кинәт начарланып китте, хәтта суга барырга да өлгерми калдым. Ә минем бик эчәсем килә. Иреннәрем кара көеп чыкты. Берәр чиләк су гына алып кайтчы, балам.

Малай үзен кызыклы уеннан бүлдергән әнисенә канәгатьсезлек белән карап:

– Суны иртән тору белән апкайтып куйсаң булмый идемени? –

дигән.

– Иртүк алып кайтсам, көне буе җылынып бетәр дигән идем. Син бит кичләрен уеннан арып кайткач салкын су эчәргә яратасың, - дигән малайның әнисе.

Малай бик авырлык белән генә суга барырга ризалык белдергән.

– Улым, - дигән әнисе аңарга, суны теге Көймә тавы артындагы чишмәдән ал. Аның суы тәмле дә, салкын да, шифалы да.

Малай чиләген күтәреп урамга чыккан. Кулын кашына куеп, Көймә тавына таба караган. Көймә тавы бик-бик еракта, зәңгәр офыклар артында булып күренгән аңа. Җитмәсә кояшы өтеп алырдай итеп кыздыра икән.

– Мондый кызуда шул тиклем еракка барып йөргәнче, суны менә шушы якындагы чишмәдән алсам да ярар әле, - дип уйлаган малай һәм, чиләген бер читкә куеп, өр-яңадан уйнарга тотынган. Үзенең бик каты эчәсе килгәч кенә, суга барырга кирәклеге искә төшкән.

Менә ул бермәлне тирләп-пешеп судан кайтып кергән. Әнисе аның чәчләреннән сыйпап:

– Рәхмәт, улым, бик зур рәхмәт, - дигән, һәм йотлыгып-йотлыгып суны эчә башлаган. Эчкән саен күкрәгендә көч арта баруын сизгән. Бераздан инде бөтенләй сәламәтләнеп киткән. Малай сөенә-сөенә урамга чыгып йөгергән.

– Белмәде, әнием суның кайсы чишмәнеке икәнлеген белмәде, - дип уйлаган ул.

Шулай дип уйлавы булган, күктә яп-якты булып янучы кояш кинәт карала башлаган. Дөнья коточкыч ямьсезләнеп киткән. Кош-кортлар куркышып ояларына качканнар. Шомлы итеп, елап-елап этләр өрергә тотынган. Малай ни уйларга да белмичә, курка-курка өенә чапкан.

– Әни, - дигән ул сулышын көчкә-көчкә алып, - нишләптер кояшның йөзе каралды. Әнә, тышка кара әле.

Әнисе кояшка караган да болай дигән:

– Кемдер бу дөньяда ялган эш кылган булырга тиеш, улым.

Кояшның шул кеше өчен оялудан йөзе каралып чыккан. Чөнки җирдә кояш күрмәгән бер генә эш тә юк.

– Әни, - дигән малай башын түбән иеп, - мин суны Көймә артындагы чишмәдән алмаган идем, гафу ит мине.

Малай мөлдерәмә яшьле күзләре белән әнисенә караган. Әнисе улын күкрәгенә кыскан. Шулвакыт кояштагы караңгылык кими башлаган. Дөнья әкренләп яктырган, кошлар кереп поскан ояларыннан чыгып, агач ботакларына кунганнар, этләр елый-елый өрүләреннән туктаган. Бар нәрсә элекке хәленә кайткан, бары тик кояштагы тап кына бөтенләй бетеп җитмәгән.

Әйе, дөньяда бер генә ялган да эзсез калмый шул. Яманлыкны хәтта кояш та яндырып бетерә алмый икән.

(Яруллин Ф. Г. Зәңгәр күлдә Ай коена - әкиятләр җыентыгы. - Казан, 1990. - 269 бит).

**Тема: Яз турында әңгәмә.**

**Фәнис Яруллинның “Кая киткән тамчылар?” шигырен ятлау.**

***Зурлар төркеме өчен.***

**Тема:** Яз турында әңгәмә. Фәнис Яруллинның “Кая киткән тамчылар?” шигырен мнемотехника ысулларын кулланып ятлау.

**Максат:** Балаларның яз турында алган белемнәрен ныгыту, якташыбызның иҗаты белән кызыксыну тәрбияләүне дәвам итү. Шигырьне истә калдыру. Сүзлек запасын баету.

**Сүзлек:** гөрләвек, лабаса, искиткеч хәл.

**Дәрес барышы:** Табышмак әйтү:

– Өй артында дөп-дөп кое казый.

– Тамчылар елның кайсы фасылында булалар?

– Алар каян барлыкка киләләр?

– Нинди яз айларын беләсез?

– Март аенда нинди бәйрәмнәр бар? *(8 Март -әниләр бәйрәме,, Нәүрүз- яз бәйрәме.)*

Безнең якташыбыз да яз аен бик ярата, язга тамчыларга багышлап бик матур шигырь язган. Шигырьне сәнгатьле итеп сөйләү.

Мнемотехника ысуллары ярдәмендә (шигырь эчтәлеге буенча рәсемнәр кулланып) шигырьне ятлау.

***“Кая киткән тамчылар”***

Тәрәзәдән кулын сузып
Бер сабый тамчы тота;
Саный: берәү, икәү, өчәү!
Ә дүрт санын оныта.
Кабат санап карарга дип
Учын ачып караса:
Искиткеч хәл, учта тамчы
Берәү дә юк лабаса.

*Фәнис Яруллин*

Сүзлек өстендә эш.

Сораулар:

1. Бер сабый нәрсә тота?
2. Ул тамчыны ничек тота?
3. Сабый ничәгә кадәр саный белә?

4. Учта тамчылар тотып буламы?
5. Кая киткән соң алар?

**Физкультминут** *“Яңгыр”.*

Шигырьне кабат сөйләү. 4-5 баладан сөйләтү.

Дәресне “Яз җитә” җыры белән тәмамлау (Җ.Фәйзи көе, Ф. Кәрим шигыре).

***“Яз җитә”***

Кояш көлеп карый безгә,
Күзләр чагыла,
Елгалардан бозлар ага
Диңгез ягына

*Кушымта:* Яз, яз, яз җитә,
Тәрәзәне ачтылар.
Тып-тып-тып итә
Эре-эре тамчылар.
Агачка кунып чыпчыклар
Чыелдашалар,
Яшькелт – кара сыерчыклар
Әй, җырлашалар.

*Кушымта:*

Тиздән шаулап яфрак ярыр
Озын ак каен,
Ал чәчәкләр алып килер
Безгә май ае.

*Кушымта: шул ук*

**Тема: Татарстанның байрагы һәм гербы турында әңгәмә.**

**Фәнис Яруллинның “Татарстан байрагы” шигырен уку.**

***Мәктәпкә әзерлек төркеме өчен.***

**Максат:** Балаларның республикабыз турындагы белемнәрен киңәйтү, аның байрагы, туграсы(гербы) белән таныштыру; аларның нигә кирәклеген, нәрсә аңлатулары

турында сөйләү. Туган илне, туган җирне ярату хисләре тәрбияләүне дәвам итү.

**Алдан эшләнәсе эшләр:** Бу дәресне үткәргәнче 2 дәрестә Татарстан һәм Казан шәһәре турында әңгәмәләр үткәрү. Ул дәресләрдә туган ил турында төшенчә бирү. Татарстанның картасын, байрагын, туграсын(гербын) күрсәтү. Казан шәһәре күренешләре сүрәтләнгән иллюстрацияләр. Татарстан турындагы видеоязмалар, китаплар, альбом күрсәтү. Г.Зәйнәшеваның "Туган ңирем - Татарстан", Х.Вахитның "Казан" шигырен уку, З.Туфайлованың "Туган ил" ("Гөлбакча" 62 бит).

**Күрсәтмә әсбаплар:** Татарстан байрагы,туграсы(гербы), картасы.

**Сүзлек:** Байрак, тугра(герб), намус, барс, калкан(щит).

**Дәрес барышы:** Республикабыз турында белгәннәрне кабатлау. Байракны күрсәтү.

Нинди төсләр барлыгын ачыклау.

Ак төс – намус төсебез. Яшел – яшәү төсе. Кызыл төс – көчебезне күрсәтә.

Һәрбер республиканың үз байрагы була. Бу – Татарстан байрагы. Һәрбер республиканың үз туграсы да була *(гербны күрсәтү)*. Анда нинди төсләр барын ачыклау.

Тугра белән байракның төсләре бер *(чагыштыру)*. Тугpада ак барс бар. Ак төс – пакълек, сафлык, тынычлык билгесе.

Барс – кош түгел. Әмма ул гербта канатлы итеп сүрәтләнгән. Сезнең канатлы елан, канатлы ат рәсемнәрен күргәнегез бардыр. Чынлыкта исә аларның да канаты юк бит. Ләкин халык үз экиятләрендә аларның аерым төрләрен канатлы итеп тасвирлаган, аларга нindидер өстен, сихри көч биргән. Гербтагы барс сүрәте дә - шундыйларның берсе. Барсның канатлы булуы – халкыбызның хыялы, сихри көче.

Канатлы барс кояш фонында. Кояш кызыл төстә - ә кызыл төс – көчле, энергияле булуны аңлата. - Туграга игътибар белән карагыз. Барсның сул ягында түгәрәк калкан (щит) сүрәтләнгән. Ул явыз көчләрдән саклану өчен.

Калкан тышында 8 таҗ яфраклы кашкарый чәчәге рәсеме (астра) – бу озын гомерле булуны белдерә. Канатлы барсның уң аягы күтәрелү-югарыга омтылу.

Гербның тышкы бөҗрасы – яшел төстә, аңа алтын белән үсемлек рәвешендәге лалә чәчәге (тюльпан) төшерелгән. Лалә язын беренче булып шытып чыга, җирне яшәртә, яңарта. Ул-яңарыш чәчәге. Димәк, республикабыз яңара.

Татарстаныбызның гербы да, байрагы да табигатьнең иң гүзәл якларын үзенә җыйган.

**Физминут:** “Шаян балалар”. *(Балалар ирекле басалар. Шигырьнең сүзләренә туры китереп хәрәкәтләр ясыйлар).*

Бигрәк шаян инде без,
Тик тормыйбыз бер дә без
Чүгәлибез, торабыз
Башны уңга борабыз
Аннан сулга карыйбыз.
Һәм сикерә башлыйбыз
Кулларны күтәрәбез,
Аннары төшерәбез.
Шул арада иелеп,
Басарга өлгерәбез,
Тирән итеп сулыйбыз,
Ял итәргә туктыйбыз.

Безнең якташыбыз Фәнис Яруллин “Татарстан байрагы” исемле шигырь язган. *(Шигырьнең бер өлешен уку – “Мәгариф” 8нче номер, 1977 ел, 36 бит).*

...Өч төс балкый
Безнең бу байракта:
Ак төс – безнең намус төсебез.
Яшел төсе – безнең яшәү төсе.
Кызылында чагыла көчебез...

Балаларга сораулар:

1. Фәнис Яруллин шигырь юлларын нәрсәгә багышлаган?
2. Байрактагы төсләрне ничек тасвирлаган?
3. Алар нәрсәне аңлата?
4. Кашкарый һәм лалә чәчәкләре нәрсәне аңлата?

**Йомгак ясау.**

Җавапларны тулыландыру, гомумиләштерү. Шигырь юлларын кабат уку, истә калдырырга ярдәм итү.

**Тема: Фәнис Яруллиның “Зәңгәр күлдә ай коена” исемле әкиятен сөйләү.**

***Мәктәпкә әзерлек төркеме өчен.***

**Тема:** Якташыбызның иҗаты белән таныштыруны дәвам итү. Әкиятнең эчтәлеген аңлап, сорауларга дөрес, тулы җавап бирә белүне ныгыту. Әхлакый тәрбия бирү өстендә эш: кыюлык, ярдәмчелек, тәүфыйклылык, миһербанлылык хисләре тәрбияләү. Җөмләләрнең дөрес төзелүенә игътибар итү.

**Сүзлек:** төнбоек, бака ефәге, чуртан, гөберле бака.

**Күргәзмә әсбаплар:** әкиятләр җыентыгы, әкияткә рәсем.

**Дәрес барышы:** Балалар белән моңа кадәр укыган әкиятләрен искә төшерү. Әкиятләр җыентыгын күрсәтү. Җавапларны тулыландырып, Фәнис Яруллинның балаларны бик яратуын, әкиятче булуын, алар өчен күп әкиятләр язуын әйтеп үтү.

“Зәңгәр күлдә ай коена” әкиятен сөйләү.

Дәрес барышында рәсемне күрсәтеп, сүзлек өстендә эш.

**Физминут:**

Су буенда бакалар
Баталар да калкалар
Уңга да иеләләр,
Сулга да иеләләр.
Аннары барысы бергә
Сикерешеп алалар.

**Сораулар:**

1. Ай безгә ни өчен кирәк?
2. Ул нинди бәлага дучар була?

3. Чуртан балыгы белән Гөберле бака айга ярдәм итмичә дөрес эшлиләрме?

4. Сезнең тешегез авыртканда ярдәм сорасалар сез нишләр идегез?

5. Айсылуны без нинди диябез?

6. Ярдәмчел булганы өчен Ай Айсылуга нинди яхшылык эшли?

Балалардан тулы җаваплар таләп итү. Җавапларны тулыландыру.

**Йомгаклау.**

Фәнис абый бу әкиятне балалар да Айсылу кебек кыю, ярдәмчел, тәүфыйклы, миһербанлы булып үссеннәр дип язган.

Мәкаль әйтү: “Яхшылык җирдә ятмый”.

**Зәңгәр күлдә Ай коена.**

*Фәнис Яруллин әкияте.*

Төннәрен барлык кешеләр йоклап беткәч, бакалар бакылдаудан, кошлар сайраудан, яфраклар шаулаудан, җилләр исүдән туктагач, Зәңгәр күлгә төшеп, Ай коена икән. Чөнки ул чисталыкны бик яраткан. Бөтен тәнен исле сабын белән ышкый-ышкый икән дә күлнең иң тирән җирендә чума-чума рәхәтләнә икән. Шулай әллә ничә тапкыр тәнен сабынлап, әллә ничә тапкыр чумып чыкканан соң, ул күп итеп төнбоек чәчәкләре җыярга тотына икән. Чәчәкләрнең дә төрлесен түгел, ә иң акларын, тәмам ачылып җиткәннәрен генә җыйган ул. Ике учы тулганчы төнбоек чәчәкләре җыйганнан соң, Ай, үзенең болыттан ишеп ясаган баскычының йомшак басмаларына сак кына баса-баса, күккә күтәрелә икән. Күккә менеп җиткәч, кулындагы төнбоек чәчәкләрен әле бер якка, әле икенче якка ыргытып уйнарга тотына икән. Ә ул ыргыткач төнбоек чәчәкләре күкнең түшәменә бәрелеп, йолдыз булып яна башлыйлар, ди. Әгәр төн уртасында урамга чыгып күккә карасагыз, айның учындагы чәчәкләрен күккә элеп йөрүен күрер идегез, мөгаен. Ул чагында төн көндезге кебек яп-якты була, чөнки яңа гына Зәңгәр күлдә коенып чыккан Айның тәне чип-чиста. Җилләр йоклагач, болытлар да бүредән курыккан сарык

көтүедәй чабышып йөрми, ояларында әкият тыңлап, тыныч кына ята бирәләр. Ә Айга рәхәт, ашыкмый гына дөнья гизә, йолдызлар бер-берләренә зөбәрҗәт ташлар ыргытышып уйный башласалар:

– Әй, балалар, артыгын шашмагыз. Ыргыткан ташларыгыз җиргә төшәр дә берәрсен һәлак итәр. Шуннан соң кешеләрнең безгә ачуы чыгар, - дип, йолдызларны тыеп тора икән.

Һәр көн шулай төн артыннан төн туган, күкнең биек түшәмендә йолдызлар җемелдәшкән, һәр төн шулай Зеңгәр күлдә коенырга Ай төшкән. Ә бер төнне, гадәттәгечә, Ай күлдә чума-чума коенып ятканда, кинәт кенә җил уянган, чөнки җилнең җирдәге койрыгына, ялгышып, бер сукыр тычкан китереп баскан. Җил, койрыгы авыртуга түзә алмыйча, үрле-кырлы сикергән. Аннары авырткан җиренә сулышын өрергә тотынган. Җил койрыгына шулкадәр өргән, ди, аның өрүеннән күл читендәге камышлар шаулый башлаган. Әнә шулай итеп, сукыр тычкан җилне, җил камышларны, камышлар су өстендәге дулкыннарны уяткан. Йокысыннан вакытсыз уянган дулкыннар күл өстендә галәмәт тавышлар чыгарып чабышканнар. Кайбер усалраклары күлдә үсеп торган төнбоекларны йолыккан, кайберләре, кулы авыртканчы, ярны кыйнаган, ә кайберләре су читендәге бака ефәкләрен, йолкып-йолкып, эчкәрәк, Ай коенып ята торган төшкәрәк китергән. Ай, су керүе белән мавыгып, җилнең йокыдан уянуын да, дулкыннарның, ачуланышып, төрле якка йөгерешүләрен дә күрми калган. Ә инде күргәч, судан атылып чыгыйм дигән икән, яр буеннан дулкын куып китергән бака ефәгенә уралган да калган. Ай әле тегеләй ыргылган, әле болай ыргылган, әмма бу ефәк җетмәдән ычкына алмаган. Айның тыны бетә башлаган.

– Коткарыгыз, батып үләм, - дип кычкырган ул бар көченә.

Аның тавышын иң беренче булып карт Чуртан ишеткән.

– Нәрсә төнне куркытып кычкырасың? – дигән ул Айга.

– Чуртанкай, - дигән Ай, зинһар, коткара күр. Синең тешләр бик үткен, бу ефәкне “эһ” дигәнче ерткалап атачаксың.

– Бик коткарыр идем дә, тешләрем сызлап тора шул, - дигән Чуртан, Айның батуына сөенеп. Чөнки ул Айның шундый матур, шундый якты булуына, бөтен дөньяны сокландырып торуына бик көнләшеп йөргән икән. Аннары Айның ашамыйча-эчмичә яши алуына бик тә эче пошып йөрген булган Чуртанның.

– Без монда көн саен тамак туйдыру турында уйлыйбыз, әллә кемнәрнең кармакларына эләгәбез. Ә син эшләмичә рәхәт кенә яшисең,- дигән Чуртан.

– Минме эшләмим? – дигән Ай. - Мин, беләсең килсә, төне буе бөтен дөньяны яктыртам. Мин булмасам, төнге юлчылар барыр юлларын таба алмаслар, диңгезләрдә кораблар батар, караңгыда юлбасарлар, караклар бер гөнаһсыз кешеләрне таларлар иде.

Чуртан аның сүзен бераз гына тыңлап торган да Айның һаман саен тирәнрәк баруын күреп, бәладән башаяк дип китеп барган. Ай тагын бар көчен җыеп кычкыртан:

– Коткарыгыз, батып үләм.

Бу юлы Айның тавышын бик тә чатан аяклы, карлыккан тавышлы бер Гөберле бака ишетеп килгән.

– Әй, син нәрсә, - дигән ул Айга, - безнең ефәкне урларга килдеңме әллә?

– Коткарчы, зинһар, -дигән Ай, тыным бетә. Күктә ялтырап торыр вакытым җитә. Кешеләр күктә минем юклыкны күрерләр дә хафага калырлар. Ә минем кешеләрне бер дә кайгыга саласым килми.

– Ярар, коткарырмын, дигән Гөберле бака, тик башта син минем тавышымны тыңлап кара. Матур сайрыйммы мин?

Бака әллә нинди тавышлар чыгарып бакылдарга тотынган.

Аның тавышы авызына су кабып гөбердәткән кешенеке кебек гебердәгән-бакырдаган.

– Йә, матур сайрыйммы? – дигән Гөберле бака.–Тавышым минем сандугачныкыннан маруррак бит, әйеме?

– Сандугачныкыннан матур дип булмый инде анысы, - дигән ялганларга өйрәнмәгән Ай. – Ләкин син аңа бер дә

борчылма. Син бит бака: баканың үз жыры, сандугачның үз жыры.

– Ә-ә, шулаймы? – дигән Гөберле бака. - Әгәр бөтен күлгә ишеттererлек итеп, “Гөберле баканың тавышы сандугачныкыннан матуррак” дип кычкырмасаң, синә бу күлдән чыгу юк. Йә, кычкырасыңмы, мин көтәм. Өчкә хәтле санаганчы, авызыңны ачалмый торсаң – китеп барам. Йә, башладык: бер... ике...өч...

– Юк инде, - дигән Ай, - мин ялганлый алмыйм. Ялганласам минем йөзем каралачак, ә кара йөзле Айның кемгә кирәге бар?

– Алайса, үзеңә үпкәлә, дигән дә китеп барган Гөберле бака.

Ай, соңгы көчен җыеп, тагын кычкырып җибәргән:

– Әй-йәй-ий! Коткарыгыз,батып үләм...

Бу Зәңгәр күл буенда гына бер балыкчы яши икән, балыкчының Айсылу исемле кызы булган. Шушы балыкчы кызы Айсылуның ни өчендер ике як битендә дә уч төбе кадәрле кап-кара миң үскән булган. Үзенең шул миңнәреннән оялып, Айсылу урамга да төннәрен генә чыга икән. Менә шушы Айсылу исемле кыз, күл буенда:

Битләремдәге миңнәрем
Бетми күпме юсам да,
Бәхетлерәк булыр идем,
Бака булып тусам да, -

дип, моңаеп җырлап йөргәндә, Айның ярдәм сорап кычкырганын ишеткән. Ишеткән дә, аны-моны уйлап тормастан, күлгә таба йөгергән.

Айның ныклап кычкырыр хәле дә калмаган булган. Ул бер баткан, бер калыккан.

– Әй, сөйкемле Ай, матур Ай, - дигән Айсылу, - әз генә түз. Мин хәзер...

– Кыз бөркәнеп чыккан шәлен иңеннән алып ыргыткан да, йөзә белмәвен дә онытып, суга ташланган. Тик аның үзенең дә кулларына, муеннарына бака ефәге уралган. Әмма кыз үзе турында уйламаган, тизрәк Айны коткарырга тырышкан. Калын

бака ефәген ул бөтен көченә ерткаларга, өзгәләргә тотынган. Менә бермәлне ефәк арасыннан Айның түп-түгәрәк, яп-якты йөзе күренгән.

– Рәхмәт, чибәркәй, - дигән Ай чын күңеленнән, - коткардың.

– Алай әйтмә, - дигән Айсылу, - мин чибәр түгел, мин ямьсез кыз. Шул ямьсезлегемнән оялып, мин көндезләрен урамга да чыкмыйм.

Ай үзенең баскычы буйлап күккә таба үрмәли башлаган, Айсылуга әллә нинди матур сүзләр әйтәсе килгән аның, ләкин вакыты бик аз калган булган. Чөнки, күккә менеп, йолдызларны кабызыр вакыт җиткән. Күккә менеп җитә язгач, ул түбәнгә караган да Айсылуга болай дип кычкырган:

– Чибәркәй дип ялганламадым. Син, чынлап та, дөньяда иң-иң чибәр кыз. Әгәр минем сүзләремә ышанмасаң, йөгереп, өеңә кайт та көзгегә кара.

Кыз, йөгерә-йөгерә, өенә кайткан. Ут кабызган. Курка-курка, көзге каршына килгән. Озак кына көзгегә карарга йөрәге җитми торган. Ә караса... Ә караса, көзгедә гүзәлләрнең гүзәле бер кыз басып тора икән.

– Мин түгелдер, бу бүтән кыздыр, - дип, Айсылу үзенең битләренә кагылган, көзгедәге кыз да шул ук хәрәкәтләрне кабатлаган. Айсылу озын толымнарын сүтеп, иңнәренә тараткан, көзгедәге гүзәл дә шуны эшләгән. Бик озак ышана алмаган Айсылу моның үзе икәнлегенә.

– Битемдәге олы ямьсез миңнәр кая китте икән соң? – дип уйлаган ул.

Мин дә башта, кызның миңнәре кая китте икән соң, дип уйлаган идем. Хәзер белдем инде. Ай аның йөзенә, үзен коткарган өчен, якты нурларын ягып калдырган икән. Шуңа хәзер матур кызларга:

Ай туганда тудыңмы әллә,

Ай нуры бар йөзеңдә, - дип җырлыйлар бит. Ә Ай үзенең якты нурын бары тик күңеле матур кешеләрнең йөзенә генә яга ала. Чынлап әйтәм. Әгәр минем сүзләремә генә ышанмасагыз, кемгә дә булса яхшылык эшләп карагыз, шунда сез, Айның

тылсымлы нурларында коенгандай, матурланып китүегезне күрерсез.

(Яруллин Ф.Г. Зәңгәр күлдә Ай коена - әкиятләр җыентыгы.- Казан,1990 –183 б.)

**Тема: Фәнис Яруллинның “Ике тамчы” әкиятен сөйләү.**

***Мәктәпкә әзерлек төркеме өчен.***

**Тема:** Фәнис Яруллинның “Ике тамчы” әкиятен сөйләү.

**Максат:** Якташыбызның әкиятләре белән таныштыруны дәвам итү. Табигать күренешләре арасындагы иң гади бәйләнешләрне аңларга булышу. Әкият ярдәмендә тырыш һәм дус булганда гына үз теләгеңә ирешергә мөмкинлекне аңлату. Мәкальне истә калдыру.

Сүзлек: чык (роса), су патшалыгы, челтер- челтер, чишмә.

***Дәрес барышы:***

– Балалар, бүген мин сезне якташыбызның тагын бер әкияте белән таныштырам. Әкиятне сөйләгәнче тамчылар турында сөйләшеп алыйк әле. Нинди тамчылар була икән? Үткән дәрестә ятлаган шигырьдә нинди тамчылар турында сүз бара? *(Түбәдәге кар эреп тамган тамчы турында).* Тагын су тамчысы була. Ә чык тамчысы турында ишеткәнегез бармы? Иртән торганда үләндә, яфракларда чык була.

Менә бүген мин сөйлисе “Ике тамчы” әкияте дә шушы ике чык тамчысы турында.

*Әкиятне сөйләү **(“Гөлбакча” 188 бит).***

Сүзлек өстендә эш.

Сораулар:

1. Ике тамчы нәрсә турында сөйләшкәннәр?
2. Су патшалыгында аларга охшаганмы?
3. Җир астыннан ничек чыкмакчы булганнар?
4. Аларга чыгарга нәрсә ярдәм иткән? *(тырышлык, дуслык)*

*Җавапларны тулыландырып гомумиләштерү.*

**Физкультминут :** (Ф.Яруллинның “Кая киткән тамчылар?” шигыре буенча хәрәкәтләр ясау) **Тәрәзәдән кулын сузып,**

Бер сабый тамчы тота;
Саный: берәү, икәү, өчәү!
Ә дүрт санын оныта,
Кабат санап карарга дип
Учын ачып караса:
Искиткеч хәл, учта тамчы
Берәү дә юк лабаса.

**Мәкальне әйтү:**“Тырышкан табар, ташка кадак кагар” *(кыскача әңгәмә).*

**Йомгак ясау.**

**Тема: Фәнис Яруллиның “Алабай белән Соры ” экиятен сөйләү.**

**Максат:** Якташыбызның экиятләре аша балаларга әхлакый тәрбия бирүне дәвам итү. Тугырылыклы, сабыр булу хисләре тәрбияләү. Әкиятнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү. Этләр турындагы белемнәрен арттыру.

**Сүзлек:** тугырылыклы, хыянәтче, түзем, сабыр, җәза.

**Күргәзмә әсбаплар:** экиятләр җыентыгы.

**Дәрес барышы:** Этләр турында кыска гына әңгәмә.

- Нинди эт исемнәре беләсез?
- Кемнәрнең этләре бар?
- Сез аларны яратасызмы? Ни өчен?
- Этләр безгә нинди файда китерәләр?
- Соры, Алабай исемнәрен ишеткәнегез бармы?

Әкиятне тәкъдим итү, сөйләү. Сүзлек өстендә эш.

**Физминут.** “Кызыклы шәкерт” Т.Тукай (“Сабыйга” 36 бит).

Бер бала түгәрәк уртасына баса һәм шигырьне сәхнәләштерәләр. Калган балалар Акбай булалар. Келәмгә ятып мәтәлчек аталар.

**Сораулар:**

1. Сезгә этләрнең кайсысы охшады?
2. Ә нигә Соры түгел?
3. Алабай нинди булуы белән охшады? (түзем, сабыр, тугырылыклы).
4. Хыянәт итү яхшымы?
5. Хуҗасына хыянәт иткән өчен Соры нинди җәза ала?
6. Этегез булса нинди исем кушар идегез?

Җавапларны тулыландыру, гомумиләштерү.

Хәрәкәтле уен “Буш урын”. Бу уенны Фәнис абый кечкенә чакта бик яратып уйнаган.

**Йомгак ясау.**

**“Алабай белән Соры”**

*Фәнис Яруллин әкияте*

Бер кешенең ике эте бар икән. Этләрнең берсе ала, икенчесе соры булганга Хуҗа этләрнең берсенә Алабай, икенчесенә Соры дип исем кушкан. Алабай белән Соры Хуҗага тугры хезмәт итеп килгәннәр. Хуҗа аларны кайвакыт үзе белән ауга алган, кайвакыт өй сакларга калдыра торган булган.

Ул чакларда әле кешеләр иген чәчеп үстерү дигән нәрсәне белмәгәннәр. Гел ауга йөргәннәр. Шуның белән тамак туйдырганнар, өс-баш әзерләгәннәр. Ләкин кайвакыт ауга барган чакларда аучыларга бик кечкенә кәҗә бәтиләре, хәлсез болан бозаулары очрый икән. Аучылар аларны өйләренә алып кайтып кулга ияләштергәннәр. Безнең әлеге Хуҗаның да бик күп кәҗә бәтиләре булган. Беркөнне ул җәя белән угын алган да Алабай белән Сорыга болай дигән:

– Мин хәзер ауга китәм, дусларым, сез өйдә калырсыз. Кәҗә бәтиләрен болынга алып чыгып ашатырсыз. Кич белән мин озак кайтмый торсам, бәтиләрне өйгә алып кайтыгыз, юкса алар урманга таралышып бетәрләр.

Алабай белән Соры үзләрен ауга алмаганга Хуҗага үпкәләп калганнар.

– Мин бит озакка түгел, - дип юаткан аларны Хуҗа. – Кич булмаса иртәгә иртән әйләнеп кайтырмын. Әгәр инде кояш әнә теге тау артыннан өч тапкыр чыгып, Тирәнкүлгә өч тапкыр баткач та кайтмасам, мине эзләргә чыгарсыз.

Хуҗа үзенең этләренә бар булган азыгын салган да чыгып киткән. Алабай белән Соры тамак туйдырып алганнан соң бераз черем итәргә ятканнар.

– Хуҗа әле тиз генә кайтмый, нигә ашыгырга? – дигән Соры, Алабайның тынычсызлана башлавын күреп.

– Ярый да безнең тамакларыбыз тук, - дигән Алабай, - ә бит кәҗә бәтиләре кичә кичтән бирле берни ашамаган. Әнә алар ничек бәэлдиләр.

– Хуҗа югында ял итмәсәк, безгә гел-гел мондый җай чыгып тормас, - дигән Соры.

– Син теләсә нишлә - мин бәтиләрне болынлыкка апкитәм, - дигән Алабай.

– Ярар инде, ярар, синеңчә булсын, - дигән Соры һәм Алабай белән бәтиләр көтәргә чыгып киткән.

Көне буе алар күңелле итеп бәти саклаганнар. Кич кайтуга Хуҗа безне тәмле сыйлар әзерләп көтеп торыр дип өметләнгәннәр. Әмма Хуҗа кайтмаган. Алабай белән Сорының ашыйсылары килә башлаган. Ә өйдә ашарга нәрсә юк икән.

Кояш тау артыннын ике тапкыр күтәрелеп Тирәнкүлгә ике тапкыр баткан. - Юк, мин бүтән түзә алмыйм, - дигән Соры. – Ашыйсым килә, ашыйсым.

– Минем дә ашыйсым килә, - дигән Алабай, - Әйдә, без болай итик...

– Ничек?

– Бер-беребезгә әкият сөйлик. Бәлки, ашыйсы килү онытылыр.

Алабай белән Соры чиратлашып әкият сөйләргә тотынган. Ләкин боларның һәр әкияте үзләренең элек кимергән сөякләре, ашаган ашлары белән тәмамлана икән.

Кояш тау артыннан өченче тапкыр күтәрелеп Тирәнкүлгә өченче тапкыр баткан. Хуҗа кайтмаган.

– Хуҗаны эзләргә барырга вакыт җитте, - дигән Алабай.

– Минем бер адым атлар хәлем дә юк, - дигән Соры. - Әллә соң юлга чыгар алдыннан берәр кәҗә бәтиен ашап алабызмы?

– Син нәрсә? – дигән Алабай. – Хуҗа кайткач аның күзенә ничек карарбыз? Без бит каравылга калган сакчылар.

– Калдырсын иде ашарыбызга күбрәк, - дигән Соры.

– Үзенә дә юкны ничек безгә калдырсын? Күреп тордың бит: өйдә бер кабымлык нәрсә калмаган иде, - дигән Алабай.

– Ә кәҗә бәтиләре? – дигән Соры. - Соң алар бит әле бик яшьләр.

– Миңа яше дә ярый, - дигән Соры һәм бәтиләр янына чапкан.

Бәтиләр аны үзләренең сакчысы итеп, сөенечтән бә-ә, бә-ә килеп каршы алганнар. Соры үлән утлап йөрүче бер бәтине эләктереп, эһ дигәнче ботарлап ташлаган. – Юләр булма, әйдә, син дә эләктер берне, - дигән ул Алабайга. – Бик тәмле. Соры телләрен ялмап куйган: - Күз күрде – тамак туймады, тагын берне ашыйм әле булмаса, - дигән ул.

Ләкин шулвакыт Алабай аның балтырыннан каптырып алган:

– Җибәрмим, - дигән ул тешләрен Сорыга батырып, бәтиләргә кагыласы булма. - Ә-ә, син шулаймы әле, - дигән Соры. – Хуҗага ялагайланмакчы буласыңмы? Ләкин белеп тор: ул ялагайларны яратмый.

– Ялагайлык түгел бу, тугрылык, - дигән Алабай. – Гомер буе тугры булдым, хәзер генә хыянәт итмим. Хыянәт иткәнче мин ачтан үләм. - Үләсең килсә, үл, - дигән Соры, - ләкин минем яшисем килә.

Шулай дип ул янә бәтиләргә ташланган. Сорының мондый әшәкелегенә, мондый хыянәтенә Алабай түзеп тора алмаган, бөтен көче, бөтен ярсуы белән Соры өстенә ыргылган. Бик каты сугыш киткән. Әле Соры аста калган, әле – Алабай. Үзләренең

сакчыларының пыр тузып, канга батканчы сугышуларын күреп, кәҗә бәтиләре хәтта үлән утлаудан туктап торганнар.

Көчләр тигез булмаган. Алабай торган саен хәлсезләнә барган. Яшь бәти ашап көч җыйган Соры Алабайны аякка басмаслык хәлгә китереп ташлаган. Үзенә каршы төшәрлек көч калмагач Соры тагын да ныграк явызланган. Берничә бәтине ашап тамагы туйганнан соң ул хәзер бүтәннәрен буып-буып ташлый башлаган. Чөнки бер мәртәбә тере җан иясенең итен ашап караган җанвар явызның явызына әйләнә икән. Хуҗа кайтып кергәндә Соры соңгы бәтине буып ята торган булган.

– Ах син, явыз җан! – дигән ул Сорыга һәм атып үтерергә теләп угын төзәгән. тик ул җәясен тартып өлгергәнче Соры Хуҗаның өстенә ыргылган. Аяктан егып салган. Чөнки Хуҗа уңышсыз аудан соң үзе дә бик хәлсезләнгән булган. Соры аның киемнәрен теткәләп бетергән, әллә ничә җирдән тәнен җәрәхәтләгән. Бәлки әле бөтенләй буып ук ташлаган булыр иде, әмма шул вакыт бераз хәл алган Алабай Хуҗасын якларга килеп җиткән. соры куркып урманга качкан. Шул көннән алып ул инде гел урманда яши башлаган, үзеннән көчсез киекләрне тотып тамак туйдырган. Кешеләрнең күзенә чалынмаскарак тырышкан. Чөнки һәр кеше аңа үзенең элекке Хуҗасы булып күренгән. Тора-бара аның элекке исеме онытылган. Аны Бүре дип йөри башлаганнар.

Хуҗа белән Алабай әкренләп терелгәннәр. Яралары ябылган. Алар бергәләп ауга йөргәннәр. Шул көннән башлап аучының тормышы әйбәтләнеп киткән. Ә Соры кайвакыт үзенең элекке тормышын сагынып аучылар яши торган урынга килә икән дә озак итеп карап тора икән. ләкин Алабай бу хыянәтчене исеннән ук сизеп өрергә тотына икән. Ә Бүре, бер хыянәт иткәч яңадан үзенә кешеләрнең ышанмаячагын белеп,аяк тавышлары ишетә башлауга урманга кача икән.

(Яруллин Ф. Г. Зәңгәр күлдә Ай коена - әкиятләр җыентыгы. - Казан, 1990. - 135 б.).



**Фәнис Яруллинның әкиятләре буенча викторина**
**(мәктәпкә әзерлек төркемнәре өчен)**

**Тема: Фәнис Яруллинның әкиятләре буенча викторина.**

**Максат**. Балаларның якташыбызның тормыш юлы һәм иҗаты турында алган белемнәрен ныгыту һәм киңәйтү, әкиятләрнең эчтәлеген һәм исемен белүне ныгыту. Әкияттәге уңай һәм тискәре геройларга дөрес бәя бирергә өйрәтү, әкиятләре аша балаларга әхлакый тәрбия бирүне дәвам итү.

**Җиһазлау.** Урындыклардан төзелгән автобус, күл – зәңгәр тукыма, татар кызы өчен милли кием, эт битлекләре – Соры һәм Алабай; тиен битлеге – тиен малае Тим-Тим; малайга милли кием һәм чиләк, урман – берничә чыршы яки агач.

**Алдан эшләнгән эшләр.** “Зәңгәр күлдә ай коена”, “Соры белән Алабай”, “Тиен малае Тим-Тим”, “Кояштагы тап” әкиятләрен сөйләү, әңгәмә һәм сүзлек өстендә эш. Музыка дәресендә “Рәхмәт сезгә” җырын өйрәнү. Шигырьләр,

мәкальләр, уеннар өйрәнү. Балаларны әкиятләрне сәхнәләштерергә өйрәтү.

**Дәрес барышы.** Балалар, буген сезнең белән якташыбыз Фәнис абый Яруллин язган әкиятләр иленә сәяхәткә чыгабыз. Ә инде сәяхәткә автобус белән китәрбез. ( Утыралар).

Автобуста сөйләшеп бару:

- Кем соң ул Ф.Яруллин?

(Шагыйрь, якташыбыз).

- Ул кайда туып үскән?

(Кызылъяр авылында).

- Хәзерге вакытта кайда яши?

(Казан шеһәрендә).

- Нинди төр әсәрләр яза?

(шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр, пьесалар).

Еракта зәңгәр күл күренә (зәңгәр җәймә, аның кырыенда милли кием кигән кыз утыра). Автобустан төшеп кыз янына киләбез.

- Синең исемең ничек? Нишләп утырасың син монда?

- Минем исемем Айсылу. Мин Айга ярдәм иттем дә ул минем битемдәге миңнәремне бетерде. Хәзер инде мин көндезләрен дә күл буена килә алам.

- Балалар, кайсы әкияттән микән бу кыз? Ул әкиятне кем язган?

(“Зәнгәр күлдә ай коена”, Ф. Яруллин язган). – Айсылуны без нинди дибез? (Кыю, ярдәмчел, тәүфыйклы, миһербанлы).

- Сезнең аңа ошыйсыгыз киләме?

- Балалар, сәяхәтебезне дәвам итәбез. Мәрхәмәтле, шәфкатьле булганы өчен Айсылуны да үзебез белән алабыз. Без әле Ф.Яруллин сүзләренә язылган җырлар да беләбез. Әйдәгез, “Рәхмәт сезгә” җырын җырлап алыйк.

**Луиза Батыр-Болгари көе.**

Кайсыгызга карарга да.
Белмибез без, белмибез без,
Сез үзегез аландагы
Иң гүзәл гөл, иң гүзәл гөл
Кушымта:

Рәхмәт сезгә, рәхмәт матур булган өчен
Йөзегезгә таң нурлары
Җыйган өчен.
Гөлләр шиңми, гөлләр сулмый
һичбер вакыт, һичбер вакыт
Бер-береңә караганда
Гел яратып, гел яратып

- Менә урманга килеп тә җиттек.

(Урман эченнән тарткалашып ике эт килеп чыгалар).

- Җибәрмим, бәтиләргә кагыласы булма.

- Ә - ә, син шулаймы әле. Хуҗага ялагайланасыңмы? Ләкин белеп тор: ул ялагайларны яратмый.

- Ялагайлык түгел бу, тугрылык, гомер буе тугры булдым, хәзер генә хыянәт итмәм. Хыянәт иткәнче мин ачтан үләм.

- Балалар, бу ике эт кайсы әкияттән?

("Соры белән Алабай").

- Соры хуҗасына хыянәт иткәне өчен нинди җәза ала?

(Ул тора-бара Бүрегә әверелә).

- Ә хәзер урман аланында уйнап алыйк әле.

"Миңлебай" уены. ("Ал кирәк, гөл кирәк", 44 бит.)

(Уен беткәндә генә сикереп тиен килеп чыга).

- Мине дә уйнатыгыз әле узегез белән. Минем хәзер иске дусларым калмады, яңа дуслар кирәк миңа. Моннан соң мин дусларымның кадерен белермен, әйткән сүземдә торырмын.

- Балалар, кайсы әкияттән килде микән бу тиен малае?

("Тиен малае Тим-Тим").

- Аның белән дус буласыгыз киләме?

(Юк, ул сүзендә тормый,дусларының кадерен белми).

- Балалар, без Тим-Тимгә ышаныйк инде. Ул бит сүз бирде. Утыртып балалар бакчасына алып кайтыйк та сынап карыйк. Бергә-бергә тәрбияләрбез.

(Автобуска утыралар. Ике эт белән тиен дә утыра).

- Сәяхәтебезне дәвам итәбез. Якташыбызның берничә шигырен искә төшереп алыйк әле.

**Кая киткән тамчылар?**
Тәрәзәдән кулын сузып,
Бер сабый тамчы тота;
Саный: берәү, икәү, өчәү!
Ә дурт саны оныта.
Кабат санап карарга дип
Учын ачып караса:
Искиткеч хәл, учта тамчы
Берәү дә юк ләбаса!

**Бияләй**
Бияләйдә бармаклар бит
Җылыналар кысышып.
Шуңа күрә салкында да
Алар йөрмиләр өшеп.
Тормышта да бергәләшеп
Яшәсәң генә җылы.
Катып, туңып калмыйм дисәң,
Онытма, дускай, шуны.

**Охшашлык**
- Бабакай, сиңа охшаган
Кеше күрдем урамда.
Кәкре таякка таянып
Тора иде ул анда.
- Миңа охшаган иде соң
Ул бабайның кай ягы?
- Гел синеке төсле иде
Кулындагы таягы.

(Автобусны кулына чиләк тоткан бер малай туктата). – Мине әне шул чишмәгә кадәр генә алыгызчы? Әнием бик каты авырый, эчәсе килгән. Ул суны ерак чишмәдән алырга кушты. Ул чишмәнең суы тәмле дә, шифалы да икән.

- Балалар, бу малай кайсы әкияттән?

(“Кояштагы тап”).

- Утыртабызмы аны? (Җаваплар).

- Әниеңне гел тыңласаң, ярдәм итсәң генә утыртабыз без сине. Сүз бирәсеңме?

- Мин гаебемне аңладым, төзәлермен.

- Әйдә, утыр, чишмәгә чаклы алып барабыз сине.

- Безнең сәяхәтебез ахырына якынлашты.

Балалар бакчасына кайтабыз.

- Балалар, дуслык, яхшылык турыдагы мәкальләрне дә искә төшерик:

- Бер ялганласаң, икенче ышанмаслар.

- Иптәшең үзеңнән яхшы булсын.

- Яхшылык җирдә ятмый.

- Кош канаты белән, кеше дуслары белән көчле.

- Менә кайтып та җиттек, сәяхәтебез тәмам.

Әкиятләр иленә сәяхәт ошадымы? (Җаваплар).

**Йомгаклау**

- Нинди булсаң гына сине яратырлар һәм дусларың да күп булыр?

(Тырыш, ярдәмчел, шәфкатьле, тугрылыклы, кыю, үз сүзеңдә торучан, миһербанлы, сабыр).

- Балалар, барыгыз да тормышта шундый булырга тырышыгыз.

(Вакыт калса әкиятләр персонажлары белән хәрәкәтле уеннар оештыру).



**Тема: “Зәңгәр күлдә ай коена».**

**Фәнис Яруллин әкияте буенча сәхнәләштерү өчен**

**Алып баручы:** Төннәрен барлык кешеләр йоклап беткәч, яфраклар шаулаудан, җилләр исүдән туктагач, Зәңгәр күлгә төшеп Ай коена икән.

*Ай сәхнәдә күренә, матур итеп як-ягына карап, матур итеп әйләнеп, “күлгә” төшеп “юына башлый...”*

**Алып баручы:** Ә бер төнне, гадәттәгечә, Ай чума-чума коенып ятканда, кинәт кенә җил уянган, чөнки җилнең җирдәге койрыгына ялгышып сукыр тычкан китереп баскан.

*Сәхнәгә “җил” йөгереп чыга, әйләнә-әйләнә, уфырдый.*

**Алып баручы:** Җил койрыгы авыртуга түзә алмыйча үрле-кырлы сикергән. Аннары авырткан җиренә сулышын өрергә тотынган.

*Җил койрыгына өрә-өрә читкә киткән, дулкынга тия.*

**Алып баручы:** Йокыларыннан вакытсыз дулкыннар уянган.

*Сәхнәнең “кул” күренеше белән 2 бала дулкын булып яткан җирдән торып чабыша башлылар, һәм “Яр читеннән” икесе ике яктан “бака ефәген” тотып Ай өстенә ташлыйлар, йөгереп читкә китәләр.*

**Алып баручы:** Дулкыннар яр читендәге бака ефәкләрен йолкып эчкәрәк, Ай коенып ята торган төшкә китергәннәр. Ай бака ефәгенә уралып, аның тыны бетә башлаган.

**Ай:** Коткарыгыз, батып, үләм! Коткарыгыз...

**Алып баручы:** Айның тавышы иң беренче булып Чуртан ишеткән.

**Чуртан:** Нәрсә булды, нигә кычкырасың?

**Ай:** Чуртанкай, зинһар, коткара күр. Синең тешләрен бик үткен, бу ефәкне “әһ” дигәнче ертасың.

**Чуртан:** Бик коткарыр идем дә, тешләрем сызлап тора. Мин сиңа ярдәм итә алмыйм. Бат шунда.

*Чуртан сәхнә читенә китә.*




**Алып баручы:** Чуртан Айның батуына сөенә генә икән. Чөнки ул Айның бөтен дөньяны сокландырып торуына бик көннәшеп йөргән икән. Ә Ай тагын бар көчен җыеп кычкыра икән.

**Ай:** Коткарыгыз, коткарыгыз, батып үләм...

**Алып баручы:** Бу юлы Айның тавышын бер гөберле бака ишетеп килгән.

**Бака:** Әй, син нәрсә? Безнең ефәкне урларга килдеңме әллә?

**Алып баручы:** Коткарчы, зинһар, тыным бетә.Күктә ялтырап торыр вакытым да җитә.

**Бака:** Ярар, мин сиңа булышырмын. Тик башта син минем тавышымны тыңлап кара: кыува... кыува... кыува... кыува... кыува... кыува... Йә, матур сайрыммы? Сандугачтан да матуррак бит, әйеме?

**Ай:** Сандугачтан да матур дип булмый инде анысы. Ләкин син борчылма. Син бит бака: баканың үз җыры, сандугачның үз җыры...



**Бака:** Ә-ә, шулаймы? Алайча үзеңә үпкәлә, мин сиңа ярдәм итмим.

*Бака читкә китә.*

**Алып баручы:** Шулай дип бака Айны бәләдән коткармыйча китеп барган. Ә Ай соңгы көчен җыеп тагын кычкыра икән...

**Ай:** Коткарыгыз, батып үләм!

**Алып баручы:** Ә бу Зәңгәр күл буенда гына бер балыкчы яши икән. Балыкчының Айсылу исемле кызы булган. Ул кызның ни өчендер ике як битенә дә уч төбе кадерле кап-кара миң үскән булган. Шул миңнәреннән оялып Айсылу урамга төннәрен генә чыга икән. Менә шушы Айсылу исемле кыз кул буенда.

**Кыз:** Битемдәге миңнәрем

Бетми күпме юсам да.

Бәхетлерәк булыр идем

Бака булып тусам да.

**Ай:** Коткарыгыз, коткарыгыз!

**Кыз:** Әй, сөйкемле Ай, матур Ай, әз генә түз, мин хәзер коткарам сине...

**Алып баручы:** Кыз бөркәнеп чыккан шәлен иңеннән алып ыргыткан да, йөзә белмәвен дә онытып, суга ташланган. Кыз үзе турында уйламаган, тизрәк Айны коткарырга тырышкан.

**Ай:** Мине коткарган өчен рәхмәт сиңа чибәркәй.

**Кыз:** Алай димә, мин чибәр түгел...

**Ай:** Син чынлап та иң-иң чибәр кыз. Әгәр минем сүзләремә ышанмасаң, көзгегә кара.

*Кыз кул болгап Айны озата, кесәсеннән көзге алып тамашачылар ягына борылып көзгегә карап әйтә...*

**Кыз:** Битемдәге ямьсез миңнәр кая китте икән соң? *Сәхнә читенә китә*

**Алып баручы:** Тамашачылардан сорый: Ә сез ничек уйлыйсыз? Кая китте икән Айсылуның ямьсез миңнәре?

Әйе, үзен коткарган өчен Ай якты нурларын ягып калдырган икән. Шуңа хәзер иң матур кызларга:

Ай туганда тудыңмы әллә,
Ай нуры бар йөзеңдә,- дип җырлыйлар бит.

Чын-чын... Әгәр минем сүзләремә ышанмасагыз кемгә дә булса яхшылык эшләп карагыз. Шунда сез дә Айның тылсымлы нурларына коенгандай матурланып китүегезне күрерсез.

**Фәнис Яруллинның "Тиен малае Тим-Тим" әкияте буенча** мәктәпкә әзерләк төркемнәрендә сәхнәләштерү өчен

(Әкиятнең эчтәлеге мәктәпкәчә яшьтәге балаларга җайландырып алынды).

Катнашалар:



1. Тиен малае - Тим-Тим
2. Кар-кар түти
3. Карга балалары
4. Керпе кызы Энәкәй
5. Төлке - Көлтә койрык
6. Чуртан балыклары
7. Сылу ай
8. Болан кызы – Биксылу
9. Куян – Төзкойрык
10. Тукран – Тук- тук Тукраныч
11. Әрлән малайлары
12. Кырмыскалар
13. Ябалак
14. Балалар.
15. Аучы.

***<u>Автор:</u>***

- Карурманның карасында, җир белән күк арасында бер биек агач башында яшәгән ди, тиен малае Тим-Тим. Көне буе ботактан ботакка сикереп уйнаган ул. Әллә үзе бик шаян һәм шук булганга дуслары-иптәшләре бик якын иткән аны. Тим-Тим иң-иң озын агачның иң-иң югары ботагына менеп бер сызгыруга, аның дуслары җыелып җитә икән.




***<u>Беренче күренеш:</u>***

Урман күренеше, еракта авыл, бер почмакта күл. Тиен малае Тим-Тим, куян Төзкойрык, керпе кызы Энәкәй, болан кызы Биксылу, әрлән, ябалак, аландагы чәчәкләр җырлы-биюле уеннар уйныйлар.

***Җырлы-биюле уеннар***

Җәнлекләр уйнап таралышалар, тиен малае Тим-Тим оясы янына килә, карга Кар-Кар түти үз оясы янында балаларын ашатып йөри, үзе тешен тоткан, ыңгыраша, авырткан теш ягыннан яулык белән бәйләп тә куя.

***<u>Кар-Кар түти:</u>***

– Әй, Тим-Тим, килче яныма?

***<u>Тим-Тим:</u>***

– Нәрсә булды, карга түти?

***<u>Карга:</u>***

– Беразга минем балаларымны карап тора алмассыңмы? Тук-Тук Тукранычка барып тешне суыртып кайтырмын дигән идем.

***<u>Тим-Тим:</u>***

– Бар, бар, рәхәтләнеп суырт, - балаларыңны карармын, ояңны туздырмам.

***<u>Кар-Кар:</u>***

– Менә рәхмәт, юкса кемгә әйтергә икән дип иртәдән бирле баш вата идем.

***Тим-Тим:***

– Мин барында бер дә кайгырма, Кар-Кар түти.

***Карга:***

– Хәзер кайгырмыйм инде, күңелем тынычланды. Син бик әйбәт бит, сүз

тыңлаучан. Минем балаларым да синең кебек әйбәт булып үсәрләр. Мин аларга кичләрен тиен малае Тим-Тим турында хикәятләр сөйләрмен. Тим-Тим шикелле ярдәмчел булыгыз диярмен.

***Тим-Тим*** бу сүзләрдән бик канәгать булып:

– Бүтәннәргә ярдәм итү рәхәт кенә ич ул, - дигән.

***Кар-Кар*** балаларының авызларына җим каптырган да :

– Карагыз аны, Тим-Тим абыегызның сүзен тыңлагыз, бик чыркылдашмагыз, юкса әнә теге тауда бөркетләр мыжлап тора. Тавышыгызны ишетеп килеп тә җитәрләр *(очып китә).*

***Тим-Тим*** имезлекле шешәләргә су салып карга балаларының һәр берсенә биреп чыга:

– Елашмагыз, әнкәгез хәзер кайтып җитәр.

Агач арасыннан куян Төзкойрык килеп чыгып физзарядка ясый башлый.

***Тим-Тим:***

– Нишлисең анда, әй, Төзкойрык?

***Төзкойрык:***

– Физзарядка ясыйм бит, күрмисеңмени?

***Тим-Тим:***

– Нигә ясыйлар соң ул физзарядканы?

***Төзкойрык:***

– Һи, надан. Шуны да белмисең. Физзарядканы аны көчле булыр өчен ясыйлар.

***Тим-Тим:***

– Ә көч нәрсәгә кирәк?

***Төзкойрык:***

– Көчне аны, дустым, беренче чыгар өчен сынашалар. Көчлеләргә бөтенесе баш ия.

(Тим-Тим Кар-Карның оясы турында бөтенләй оныткан.)

**<u>Тим-Тим белән Төзкойрык бергә:</u>**

Әйдә киттек көрәшергә,
Бер җиңеп кайтыйк әле:
Аю чыкса мәйданнарга,
Баш аркан атыйк әле.

(Төзкойрык Тим-Тимне култыклап алган да җырлап китеп барганнар.)

***<u>Карга балалары:</u>***

– Әние-е-м, син кайда-а-а? Без куркабыз би-и-т, Төзкойрык та әллә кайда китте-е-е... (урман эченә кереп югалалар).

**<u>Икенче күренеш:</u>**



Аланда Тим-Тим куяннар белән зарядка ясыйлар, алар каршына

керпе кызы Энәкәй килеп чыга:

***<u>Энәкәй:</u>***

– Сез монда нишлисе-е-з?

***<u>Тим-Тим:</u>***

– Зарядка ясыйбыз, Энәкәй.

***<u>Энәкәй:</u>***

– Мине дә өйрәтегез әле?

***<u>Төзкойрык:</u>***

– Әйдә, бас безнең янга, без сине дә зарядка ясарга өйрәтәбез!

(Җәнлекләр озак кына күнегүләр ясаганнан соң, Энәкәй сөенеченннән сикерә-сикерә дусларын кунакка чакырган).

***<u>Энәкәй:</u>***

– Әйдәгез, безгә керик, салкын әйрән эчеп чыгарбыз, ял итәрсез.

(Энәкәй аларны төрле-төрле сыйлар белән сыйлаган. Озак кына кунак булып, ныклап хәл җыйгач, дуслар өйләренә кайтып китkәннәр.)

***<u>Өченче күренеш:</u>***

(Тим-Тим җырлый-җырлый өенә кайтып килгәндә, Кар-Кар түти дә кайтып җитеп балаларын тапмыйча, арлы-бирле оча-оча елый икән.)

***Тим-Тим:***

– Һәй, Кар-Кар түти, нигә елыйсың? Әллә тешеңне бик авырттырып суырдылармы?

***Тим-Тим*** (тәмам аптырашка төшеп):

– Йә инде, Кар-Кар түти. Төзәлер әле. Бервакыт минем дә тәпиемә шырпы кадалган иде, тора бара бетте. Хәзер мин менә ничек сикерә алам. Әле генә аланда Төзкойрык, керпе кызы Энәкәй белән зарядка ясарга өйрәнеп кайттым. Теләсәң сине дә өйрәтәм, - дип, төрлечә күнегүләр ясарга тотынган.

( Әмма Кар-Кар түти һаман елавын белгән.)

***Кар-Кар түти:***

– И-и-и, балакайларым минем, ерткыч авызына ризык булыр өчен дип чыгарган идеммени мин сезне?! Бигрәкләр дә матурлар иде бит бәбекәчләрем. Җим алып кайтып оя читенә басуга сап-сары авызларын ачып муеннарын суза башларлар иде матуркайларым. Өчесенә өч матур исем дә сайлап куйган идем. Никләр генә киттем икән – никләр генә шул вәгъдәсез Тим-Тимгә ышандым икән?

(Кар-Карның шулай дип елавын ишеткәч кенә Тим-Тим эшнең нәрсәдә икәнен аңлаган. Кар-Кар түтине шундый авыр хәлгә куюына ул бик-бик кыенсынган.)

***Тим-Тим:*** (ялварулы тавыш белән)

– Кар-Кар түти, берүк гафу итә күр. Яңадан гел уяу булырмын. Бу юлга гафу ит тә елама...

Кар-Кар түти аңа берни дә эндәшмәгән, хәтта Тим-Тимгә борылып та карамаган, очып киткән.

***Дүртенче күренеш:***

Шул вакыт чәчәкләр, күбәләкләр йөгереп чыгып, тыныч көйгә бию башкаралар.

***Чәчәкләр, күбәләкләр биюе.***



(Тим-Тим бию вакытында моңсуланып йөри.)

***Автор:***

Ә Тим-Тим беркадәр вакыт йөргән дә Кар-Кар турында бөтенләй онытkан. Ул тагын элеккечә ботактан ботакка сикереп уйнаган, агач башында атына-атына җырлаган. Шулай сикерә-сикерә уйнаганда ул көннәрдән беркөнне кайдадыр еракта чинап-чинап куйган тавыш ишеткән. Тавыш килгән җиргә барып караса – ни күрсен – куак төбендә төлке-Көлтә койрык тәгәрәп-тәгәрәп мәш килә икән.

***Тим-Тим:***

– Нәрсә булды, Көлтә койрык?

***Көлтә койрык:***

– Менә сунарчы капканына килеп каптым. Капканга эләккән аягым бик

сызлый, шуны һич ычкындыра алмыйм.

***Тим-Тим:***

– Бәлки мин ярдәм итә алырмын? Минем тешләр бик үткен. Шартлаттым - өздем булыр капканыңны.

***Көлтә койрык:***

– Син ярдәм итә алырсың, тик үткен теш белән генә эш барып чыкмастыр, монда акыл кирәк.

***Тим-Тим:***

– Ансы кемдә бар икән соң?

***Көлтә койрык:***

– Капкан ача торган серне минем ерак туганым Акылбай абзый гына белә. Зинһар, барып әйт Акылбай абзыйга, килсен, коткарсын ул мине.

***Тим-Тим:***

– Барабыз аны, әйтәбез аны, - дигән ул ике уйлап тормыйча һәм агач башына сикереп менеп китә дә башлаган.

***Көлтә койрык:***

– Тукта, син бит әле аның кайда торганын белмисең. Юлын өйрәтим үзеңә.

***Тим-Тим:***

– Өйрәт алайса.

***Көлтә койрык:***

– Акылбай абзыйларның өйләре урманның уң ягында, аланның сул ягында. Кыек та барма, туры да барма. Елга күрсәң сикереп үт, болын күрсәң йөгереп үт. Юлың җуйсаң айдан сора, ай юл күрсәтә алмаса, барып җиткәч аны Акылбайдан сора. Менә шул, ә хәзер тизрәк чап.

***Бишенче күренеш.***

***Автор:***

Тим-Тим Көлтә койрыкның өйрәтүе буенча юлга чыгып киткән. Кыек та бармаган, туры да бармаган. Әнә шулай бара торгач бер бик матур күл буена барып чыккан. Ә анда, мин сиңа әйтим, эре-эре чуртаннар яр читендәге комда кызынышып яталар икән. Тим-Тимнең мондый хәлне күргәне булмаган, шуңа күрә ул бик гаҗәпләнгән.

***Тим-Тим:***

– Нишлисез сез?

***Чуртаннар:***

– Комда кызынабыз бит.

***Тим-Тим:***

– Ә нигә кызыналар соң ул комда?

***Чуртаннар:***

– Чыныгырга! Әйдә, сузылып ят безнең янга, бик рәхәт нәрсә ул кояшта кызыну.

(Тим-Тим чуртаннар белән уйный-уйный комда аунаган, чуртаннарның сыртына атланып күлнең бер ягыннан икенче ягына йөзүләр аңа әйтеп бетергесез рәхәтлек биргән. Ул үзенең кая баруын, ни өчен бу күл буена килеп чыгуын тәмам оныткан. Кояшның кызуы сурәтләнеп, салкынча җил исә башлагач кына Көлтә койрык исенә төшкән аның. Исенә төшкән дә йөрәге “жу” итеп куйган. Шарт-шорт басып килүче аяк тавышлары ишетеп, артына борылган. Ә анда – син күр дә, мин күр – җилкәсенә Көлтә койрыкны салып аучы өенә кайтып бара. Тим-Тимнең, Көлтә койрыкны жәлләүдән, күзләре яшьләнгән.)

***Тим-Тим:***

– Яңадан ваемсыз булмам, биргән вәгъдәмне үтәрмен...

(Әкрен-әкрен генә китеп барган...)

***Алтынчы күренеш:***

(Бер кечкенә ачыклык. Анда кая барырга белмичә аптырап болан кызы Биксылу әле бер якка, әле икенче якка карап басып тора, аның каршына Тим-Тим килеп чыга.)

***<u>Тим-Тим:</u>***

– Нишләп торасың монда, Биксылу?

***<u>Болан кызы Биксылу:</u>***

– Адаштым. Әнкәмне нindидер ике аяклы явыз җанварлар куып китте. Ул миңа пышылдап кына: - Шушында тор, бераздан үзем килеп алырмын. Менә өч тапкыр кояш чыгып, өч тапкыр батты инде, һаман энкәем юк (елый башлый).

***<u>Тим-Тим:</u>***

– Ярар, елама әле. Бәлки, ул үзе сине эзләп йөридер. Хәзер мин агач башына менәм дә әниеңне караштырам. Әниең күренмәсә, бәлки берәр туган-тумачаңны табарбыз. Мин барында югалмассың, Биксылу.

***<u>Болан кызы Биксылу:</u>*** (яшьле күзләрен сөртеп)

– Рәхмәт, Тим-Тим абзыкай...

***<u>Тим-Тим</u>*** (үзенең шундый әйбәт эш эшләвенә сөенеп күкрәк кагып куйган):

– Без менә шундый инде, ә син елап торасың. Хәзер синең әниеңне табарбыз. Ә син шушыннан бер кая да китмә.

***<u>Болан кызы Биксылу:</u>***

– Юк, китмим. Эчәсем килсә генә әнә теге якын чишмәгә барып килермен, яме? Син әниемне күрсәң миңа килеп әйтерсең.

***<u>Тим-Тим:</u>***

– Әйтермен!

(Тим-Тим китеп барган )

***<u>Болан кызы Биксылу</u>*** ( “Әни” шигырен көйли-көйли чишмәгә таба китә):

**Әни**

*Фәнис Яруллин шигыре*

Иң матур юллар – син йөргән юллар.
Иң тәмле сулар – син биргән сулар.
Иң йомшак куллар – син сөйгән куллар.
Иң якты моңнар – син белгән моңнар.

Иң кайнар эзләр – син баскан эзләр.
Иң моңлы күзләр – син баккан күзләр.
Иң тугры сүзләр – син әйткән сүзләр.
Иң сабыр йөрәк – синең йөрәгең.
Иң талмас беләк – синең беләгең.
Иң изге теләк – синең теләгең.
Иң бөгелгән бил – ул синең билең.
Гөл сибелгән тел- ул синең телең.
Үч тотмас күңел –синең күңелең,Әни!

***<u>Җиденче күренеш.</u>***

***<u>Автор:</u>***

Тим-Тим Биксылу яныннан киткәч берничә агач башына менеп караган. Әмма һич-бер җирдә болан кызчыгының әнисен күрмәгән. Шунда, урман янындагы бер басуда, әрлән малайлары качыш-качыш уйнап йөриләр икән. Тим-Тим урманда ялгыз калган Биксылу турында бөтенләй онытып, әрлән малайлары белән качышлы уйнарга тотынган.

(Тим-Тим әрлән малайлары белән йөгерешеп качышлы уйныйлар)

Әрлән малайлары бу уенга шулкадәр остарып җиткәннәр ди, мин сиңа әйтим, әллә кайдагы чокыр-чакырларга качалар да бетәләр икән. Тим-Тим аларны эзләп хәлләрдән тайган. Ә әрлән малайлары Тим-Тим күзен йомып торган арада үзләренең ояларына кереп посалар икән дә чыгарга онытып йоклап ук калалар икән. Тим-Тим берничә көн уйнап хәлдән тайгач, ачыккач өенә кайтып киткән, юлда Төзкойрыкны очраткан.

***<u>Тим-Тим:</u>***

– Төзкойрык, әйдә безгә керәбез, үзеңне бик тәмле чикләвек белән сыйлармын. Аннары бергә-бергә уйнарбыз.

***<u>Төзкойрык:</u>***

– Рәхмәт, чикләвегеңне үзең генә аша. Мин вәгъдәсезләр белән дуслашмыйм.

(Ә Керпе кызы Энәкәй исә Тим-Тимне күрүгә тизрәк өенә кереп китү ягын караган...)

***<u>Тим-Тим</u>*** (аптырап бик озак басып торган, аннары):

– Әй, уйнамасагыз бик исем киткән иде. Мин сезгә үземнең кем икәнемне күрсәтермен әле!

(Шулвакыт ул өй салып ятучы кырмыскаларны күрә. Кырмыскалар җыйнаулашып салам, кура ише нәрсәләр ташыйлар икән)

***Тим-Тим:***

– Кая, үзегезгә ярдәм итим әле?! Бу саламны мин бер учым берьюлы күтәрә алам. Ә сез аның берсен әллә ничәү җыелып өстерисез.

***Кырмыскалар:***

– Рәхмәт, ярдәмең кирәкми. Үз сүзендә тормаганнарга без эш кушмыйбыз (янә үз эшләренә тотынганнар).

***Тим-Тим:***

– Эшләтмәсәгез бик исем китми әле. Беләсегез килсә, мин әллә кайларда куллап көтеп торалар.

***Кырмыскалар:***

– Алайса көткән җиргә кит!

(Тим-Тим юл капчыгын асып китеп бара...)

***Сигезенче күренеш.***

***Автор:***

Шулай итеп Тим-Тим карурманда япа-ялгызы калгач ерак сәфәргә чыгып киткән. Бара икән шулай, бара икән, бара торгач, имәннән чикләвек җыючы балаларга юлыккан бу. Малайларның иң йөрәклеләре дә агачның башына ук менеп җитә алмый икән. Тим-Тим юл капчыгын җиргә куйган да сикереп имән башына менеп киткән.

***Тим-Тим:***

– Ярдәм итим әлә үзегезгә. Югыйсә чикләвекләрегезнең яртысы агачында кала (Тим-Тим учлап-учлап чикләвек сипкән. Ләкин бер бала да аның чикләвегенә кагылмаган)

– Алыгыз, ал, сезнең өчен ыргытам бит мин аларны.

***Балалар:***

– Безгә вәгъдәсезләрнең чикләвеге кирәкми! (Балалар үзләре җыйган чикләвекләрне генә алалар да кайтып китәләр)

(Тим-Тимнең бик нык хәтере калган. Чикләвек җыючы балалар яныннан киткәчтен дә бик күп җан ияләренә

булышырга теләген белдергән. Хәтта әҗәл белән тартышып ятучы Ябалак та аның ярдәмен алырга теләмәгән.)

***Тим-Тим:***

– Бер уч су китереп авызыңа салыйм, бәлки рәтләнерсең?

***Ябалак:***

– Юк-юк. Су китерәм дип китәрсең дә онытырсың, ә мин өметләнеп көтеп ятармын. Син суга дип киткәч мин йомышымны башкаларга да әйтә алмам. Берәр ышанычлырак ярдәмче килеп чыгар әле. Ә син бар, юлыңда бул.

***Тим-Тим:***

– Болай яшәү мөмкин түгел, китәргә кирәк моннан. Башка җирдә мине белмиләр әле. Яңа урманда яңа дуслар табармын. Аларны инде мин бервакытта да андый кыен хәлгә куймам. Яңа дусларымның ышанычын яулар өчен бөтенесен эшләрмен! Ант итәм!!!

***Автор:***

– Инде без дә Тим-Тим белән саубуллашыйк. Сагышлансын, моңлансын. Сагыш һәм моң җанны сафландыручы саф чишмә ул. Бәлки әле, безнең Тим-Тимебез, җаны тәмам сафлангач, моң һәм җыр канатларына утырыр да туып үскән карурманына кайтыр. Күңеле сафланганын күргәч, бәлки, элекке дуслары да аңардан баш тартмас. Әйе, мөгаен, шулай булыр. Чөнки экияттә бөтенеседә әйбәт бетә бит.

**Тема: Йорт хайваннары. Сыер турында әңгәмә.**
**Фәнис Яруллинның “Муму” хикәясен сөйләү**
***(мәктәпкә әзерлек төркеме өчен).***

**Максат:** Балаларның йорт хайваннары турында алган белемнәрен киңәйтү, терлекчеләр хезмәте белән таныштыру. Терлекчелек хезмәтенең мактаулы эш икәнен аңларга ярдәм итү, аларны хөрмәтләү хисләре тудыру. Хайваннарга карата мәрхәмәтле караш тәрбияләү. Авазларны әйтү культурасын камилләштерү.

**Өстәмә эш:** Йорт хайваннарының яшәү рәвешләре сүрәтләнгән рәсемнәр карау, табышмаклар искә төшерү,

хайваннар турында хикәяләр, шигырьләр уку. “Бүре һәм көтү” уенын өйрәтү.

**Сүзлек:** Сыер савучы, терлекче, үзсүзле, иркә.

**Күргәзмә әсбаплар:** “Колхоз фермасы” картинасы, уен өчен бүре һәм йорт хайваннары битлекләре (сыер, кәҗә, сарык).

**Дәрес барышы:**

Табышмак әйтү: Үлән ашый, май ташый.

Сораулар:

1. Сыер нинди хайван?
2. Тагын нинди йорт хайваннарын беләсез?
3. Йорт хайваннары өчен азыкны кем әзерли? Терлек абзарларын кем төзи?
4. Сыерлар безгә нинди туклыклы азык бирә?

– Җавапларны тулыландыру, гомумиләштерү.

– Рәсемне элү.

*Сораулар:*

1. Сыерлар кайда торалар?
2. Фермада ни өчен сыерлар күп?
3. Аларны кемнәр карыйлар?
4. Сыер савучы ни эшли?
5. Аларның эшен нәрсәләр җиңеләйтә?

– Балаларның җавапларын тулыландырып, терлекчеләр хезмәте турында сөйләү. Аларның хезмәте бик җаваплы, мактаулы, хөрмәтле икәнен аңлату.

“Бүре һәм көтү” уены (программа 58 бит).

– Уен вакытында ө, ү авазларының артикуляциясе өстендә эш.

Балаларга безнең якташыбыз Фәнис Яруллинның авыл малае булуын, хайваннарны бик яратуын әйтеп “Муму” хикәясен сөйләү.

(“Нәниләргә бүләк” 37 бит. Казан. Татарстан китап нәшрияте 1988 ел).

**Йомгак ясау.**

**Тема: Фәнис Яруллинның «Муму» хикәясе буенча әңгәмә.**

**Тырышлык турындагы мәкальләрне истә калдыру *(мәктәпкә әзерлек төркеме өчен)*.**

**Максат:** Якташыбызның иҗаты белән таныштыруны дәвам итү. Терлекчеләр, сыер савучылар хезмәте турында алган белемнәрен ныгыту, киңәйтү. Әсәрне аңлап, эчтәлеге буенча сорауларга дөрес җавап бирергә өйрәнү. Хикәя аша балаларга әхлакый тәрбия бирү: тырыш, эшчән, уңган булырга өйрәтү. Балаларда хайваннарга карата кайгыртучанлык, мәхәббәт тәрбияләү.Татар – халык иҗаты белән таныштыруны дәвам итү.

**Сүзлек:** Мөгри, үзсүзле, сыйраклары, вәгъдә, зәгыйфь, атказанган.

**Дәрес барышы:** Узган дәрестә нинди хикәя укыганны, аны кем язганын ачыклау.

– Хикәяне уку, сүзлек өстендә эш.

Сораулар:

1. Ни өчен хикәя “Муму” дип атала?
2. Хикәянең баш герое кем?
3. Зифа сезгә ошадымы? Без аны нинди диебез? (Тырыш, уңган, эшчән, хайваннарны ярата).
4. Әгәр дә Зифаның андый сыйфатлары булмаса, ул максатына ирешкән булыр иде микән?
5. Сез хайваннарны яратасызмы? Алар өчен нинди яхшылыклар эшләгәнегез бар?

– Җавапларны тулыландыру, гомумиләштерү.

“Бүре һәм көтү” уены.

Мәкальләр әйтү:

Эш кешене төзәтә,
Ялкаулык боза.
Хезмәт иясе, хөрмәт иясе.
Эш сөйгәнгә ил сөяр.

**Йомгак ясау.**

Бу хикәя безне нинди булырга өйрәтә?

- Фәнис Яруллин үзе дә бик тырыш, эшчән. Бу хикәяне ул сезне дә Зифа кебек эш сөючән, тырыш, миһербанлы булып үссеннәр дип язган.

**Муму**

***Фәнис Яруллин***

*(Хикәя)*

– Әни, Муму бүген күпме сөт бирде? – дип каршы ала Зифа һәркөн әнкәсен.

– Безнең Муму молодец ул, кызым, ди әнкәсе, - сөтне күп бирә. Тик синең сыман үзсүзлерәк.

– Үзсүзле? Сыерлар үзсүзле буламыни?

– Була икән шул, кызым. Тәки машина белән саудырмый бит. Иркәләгәнне, сыйпаштырганны ярата. Үзең төсле инде, үзең төсле. Иркә итеп үстергәнсең.

Әйе, Мумуны Зифа карап үстерде.

Моннан өч ел элек колхозның бер сыеры берьюлы дүрт бозау китерде. Авыл өчен генә түгел, район өчен дә зур вакыйга булды бу. Газеталарага яздылар. Әмма сыер үзенең мондый данлыклы эш эшләгәнлеген белми иде, күрәсең, бозауларына артык әһәмият бирмәде. Бигрәк тә маңгаена биш тиен акча кадәр агы булган кара бозавын үги итте: яламады, янына килмәде. Бусы минеке түгелдер моның дигән сыман, гел читкә тибәрде. Кара бозау бик хәлсез иде, аягына басалмады. Торырга маташып бераз калкына да дүрт аягын дүрт якка җәеп җибәреп кире егыла иде. “Мантый алмас бу. Малкайны җәфаламыйк. Өч бозавын үстерә алса, шул җиткән, чалып ташлыйк”, - диделәр ферма эшчеләре. Ул көнне әнисенә ияреп фермага Зифа да барган иде, өлкәннәрнең “чалып ташлыйк” дигән сүзләрен ишетеп тетрәп китте. Күзләреннән яшь бәреп чыкты. “Абыйлар, апалар, - диде ул, - чалмагыз. Әнә ич ул нинди матур. Күзләрен генә күрегез, мөлдерәп тора. Ә маңгаендагы агы...”

Зифа бозауның бөтен җирен мактап чыкты.

– Алай бик яраткач, син аны үзегезгә апкайтып үстер, - диде кемдер.

– Чынлапмы? – Зифа, мондый олы бәхеткә ышанып җитмичә, әле бер савымчыга, әле икенчесенә карады. Алар арасында колхозның баш ветврачы да бар иде, Зифа ялварулы күзләрен аңа текәде: - “Бирегез, абый, аны миңа, ә ?”

– Мал булмас ул, үскәнем. Артык зәгыйфь. Әнә күреп торасың бит, үз әнисе дә яламый. Димәк, рәтләнеренә ышанмый. Хайваннар андый нәрсәгә бик сизгер булалар.

Ничек итсә итте, бозауны чалып ташларга ирек куймады Зифа. Әнисе белән алар аны бишмәткә төреп, бәләкәй чанага салып алып кайттылар. Шаянрак телле агайлар: “Моны мал итә алсаң, авылыбызның атказанган бозау караучысы исем бирдерми булмас сиңа”, - дип калдылар. Әмма Зифа аларның сүзләрен ишетмәде дә. Аның куанычы артык зур иде.

Бозауны алар мунчага урнаштырдылар. Мунча кичә генә ягылган, җылы иде.

– Әни, - диде Зифа, - бозауны мунча кертергә ярый микән?

– Белмим шул, кызым.

– Ярыйдыр, әйеме? Әнә ич аның бөтен тәне юеш, күбекләнеп тора. Мин аны хәзер җылы су белән юындырам да коры чүпрәк белән сөртәм.

– Үзең кара инде, кызым. Бозау синеке. Теләсәң нишләт. Тик артыгын тырышып җибәрмә.

Зифа шушы көннән бозау өчен җан атып йөри башлады. Шешәгә имезлек кигереп җылы сөт имезде. Мунча суынып китмәсен дип, һәркөн әз генә ягып алды. Берничә көннән бозау Зифаның аяк тавышларын таный башлады. Кар өстеннән шыгыр-шыгыр хуҗасы атлаганны ишетсә, му-му килеп тавыш бирде. Аягына басарга тырышып тыпырчынды. Гел му-му дип каршылаганга, Зифа аңа Муму дип исем кушты. Зифаның мәктәптән кайтуын Муму зарыгып көтеп тора иде. Кулына җылы сөт тотып Зифа килеп керүгә Муму мөгрәп куя: “Миңа синнән башка бик күңелсез, көннәр озын, ята-ята кабыргаларым авыртып бетә”, ди кебек ул. Зифа иркәләп аның муенын кашый, сыртын сыпыра, үзе ягымлы тавыш белән: “Мумукаем, сөекле җаным. Син озакламый аякка басарсың. Әнә ич синең

сыйракларың нинди төз, нинди матур. Җәй җиткәч мин сине Кәҗә тавына алып барырмын. Нигә андамы? Анда үлән әйбәт. Әни әйтә, Кәҗә тавы буеннан чабып кайткан үләнне сыерлар бик яратып ашыйлар, ди. Ә хәзергә син боекма, Мумукаем, яме?" - дип пышылдый.

Бозау, хуҗасының сүзләрен аңлагандай, тын гына тыңлап тора, һәм шулай гына була күрсен дигән сыман башын чайкап ала да шаянланып китеп юеш танавын Зифаның битенә төртә.

Зифаның тырышлыгы бушка китмәде, бераздан Муму аякка басты. Аннары аякларының шәплеген күрсәтергә теләпме, сикеренгәли, шаяргалый башлады: я эскәмияне төртеп аударды, я ләгән-мазарга үзенең "автографын" салып куйды.

Җәй көне Мумуны Зифа вәгъдә иткән Кәҗә тавы буйларына алып барды. Елга үзәнлекләрендә йөртте. Муму матурайды. Йоннары елык-елык итеп тора башлады. Үскән саен Зифага ныграк ияләште... Хәтта кайвакыт берәр усал малай Зифаны рәнҗетсә-нитсә, сиздерми генә килеп, теге явызны сөзеп егарга да күп сорамый иде.

Көзен Мумуны фермага илткән чакта Зифаның күзләре дымланды. Муму үзе дә, "мине монда ятлар кулына калдырасыңмыни инде ә?" дигәндәй, моңсуланып карап калды.

– Мин синең хәлеңне беләргә гел килеп йөрермен, яме, көт мине, Мумукаем, - диде Зифа, инде дәү булып үскән бозауның муеныннан кочып.

Һәм биргән вәгъдәсендә торды Зифа, гел фермага килеп йөрде. Савымчалар аны яратып: "Безнең атказанган бозау караучыбыз килгән", - дип каршы алалар иде.



Туган ягым – Баулы ягым,
Баулы ягым – таулы ягым.
Бер тавында кояш булса,
Бер тавында айлы ягым.
Туган ягым – Баулы ягым,
Елгалы һәм күлле ягым.
Урманнарың җиләкле һәм
Болыннарың гөлле ягым.
Туган ягым – Баулы ягым,
Шәфкатьле һәм таңлы ягым.
Ташларың да шундый йомшак,
Һаваларың баллы ягым.
Туган ягым – Баулы ягым,
Шанлы ягым, данлы ягым.
Тауларыңнан биеккәрәк
Күтәрелде синең даның.
Туган ягым – Баулы ягым,
Җырлы ягым, моңлы ягым.
Күзләрең дә, кышларың да
Җаннарыма җылы ягым.

1991 ел, декабрь ае. Ф. Яруллинның әнисе һәм бертуган апасы бакчабызда кунакта.



"Әби килде авылдан,
безне бик тә сагынган.

Без дә аны сагындык,
күчтәнәчкә сарылдык..."



1992 ел, июль ае. Шагыйрьнең бакчабызга беренче килүе.

"Балаларның теле –
кыңгырау
Гел чыңгылдый,
ява мең сорау..."





“Кояштагы тап” әкиятеннән күренеш. “...Мондый кызуда шул тиклем еракка барып йөргәнче, суны менә шушы якындагы чишмәдән алсам да ярар әле...” 1999 ел.



“...Әй, кызык та Илһамга,
Көлә гел чырык-чырык.
Иртән дә авыз ерык,
Кичтән дә авыз ерык.
Көлмәс иде Илһам да,
Бар җирдә кызык күрә;
Тулып ташкан бәхетне
Көлмәс җирдән көлдерә...”

Баулы шәһәре, 12нче санлы балалар бакчасы. 2000 ел.



Ф. Яруллинның "Баз бакасы" әкиятеннән күренеш (бакчабызның тәрбиячеләре сәхнәләштерә), 1994 ел.



"Зәңгәр күлдә ай коена" әкиятеннән балыкчы кызы Айсылу.



"Муму" хикәясеннән уңган кыз Зифа суга бара.

“... Бәхетле – сөелгән һәм
сөйгән кешеләр,
Бәхетле – үз кайгысын җиңгән
кешеләр,
Бәхетле – үз тавына менгән
кешеләр...”





1998 ел, февраль ае

Ходайның һәр
бирмеш көнендә
Бер матур як белән
ачылыйк:
Һәркемнең гомере
бер генә,
Яхшылык эшләргә
ашыгыйк.




Юлбарыс елында туган шагыйребезнең 60 яшьлек юбилеена багышланган тантанада безнең бакчабызның балалары чыгышы. 1998 ел.



"Анам теле".

**Ф. Яруллин шигыре**

Татар теле – анам теле,
Иң борынгы бабам теле.
Буыннардан – буыннарга
Күчеп килгән заман теле.
Анам теле – телләр теле,
Милләтемнең бердән бере.
Син булганга без дә исән,
Син булганга без дә тере.





Баулы шәһәре, 12нче санлы балалар бакчасы. 2004 ел.



"Татарстан байрагы " – Ф. Яруллин шигыре .
Җилфер-җилфер итә байрагыбыз,
Ниләр сөйли соң ул җилләргә? –
Көрәшүче татар халкыннан ул
Сәлам әйтә азат илләргә.



Өч төс балкый безнең бу байракта;
Ак төс – безнең намус төсебез.
Яшел төсе – безнең яшәү төсе,
Кызылында чагыла көчебез.



“...Әй күп безнең бакчада
Төрле-төрле чәчәкләр,
Алар бар да матурлар,
Алар бар да бик шәпләр.



Кайсы кызыл, кайсы ак
Кайсы боек, кайсы шат.
Җыеп алсаң һәммәсен
Булыр иде ун кочак.



Кай чагында шуларны
Җыймак булам чүгәләп.
Ләкин чәчәк дигәнем
Булып чыга күбәләк...”

“...Болар әле бик
бәләкәй,
Берни белми,
димәгез,
Без – замана
балалары,
Без барсын да
беләбез...”





Якташыбызның әсәрләрен сәхнәләштерү эшләре туктап тормый...





**Яруллиннар гаиләсендә кунакта. Казан шәһәре, 2008 ел**.
(Уңнан сулга: Фәнис Яруллин, Нурсөя ханым, Баулы шәһәре 12-нче санлы б/б мөдире Салимшина Р.М., Нурсия ханымның туганының кызы Хәкимова Сәүия, Баулы шәһәре 12-нче санлы б/б татар теле тәрбичесе Газизуллина Г.М. )



**Фәнис Яруллинның тантаналы юбилей кичәсеннән соң. Казан шәһәре Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры, 2008 ел.**





Якташыбыз, татар халкының корыч ихтиярлы ир-егете, Муса Җәлил,
Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре лауреаты,
Татарстанның халык шагыйре
**Фәнис ага Яруллин һәм аның тормыш иптәше Нурсөя ханым**
Баулы муниципаль районы Баулы шәһәре шигырь сөючеләре һәм
бигрәк тә безнен - 12-нче санлы “Алтынчәч” балалар бакчасы өчен иң
кадерле кунаклар.

“Серле иҗат чишмәсенә кызыклы сәяхәт”. Тәрбия һәм белем бирү процессында якташыбыз Фәнис Яруллинның әсәрләрен файдалану

Төзүче авторлар:

Р.К. Шаехова -

Г.М. Газизуллина – Баулы муниципаль районы Баулы шәһәре 12–нче санлы “Алтынчәч” балалар бакчасының югары категорияле татар теле тәрбиячесе.

Техническое редактирование и компьютерная верстка:
*Л.Ф.Осипова*